Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы
«Арча шәһәренең гомуми үсеш бирү төрендәге
6 нчы номерлы «Сандугач» балалар бакчасы»

Мәктәпкәчә яшьтәге балаларга күпмәдәниятле тәрбия бирү
буенча методик кулланма

# «Дуслык белән көчле без!»

I категорияле татар теленә өйрәтү
тәрбиячесе Шәвәлиева Г.М .

2024 нче ел

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы«Арча шәһәренең гомуми үсеш бирү төрендәге 6 нчы номерлы «Сандугач» балалар бакчасы» ныңтатар теленә өйрәтү тәрбиячесе *Шәвәлиева Гөлнара Мөбәрәкҗан кызы* тарафыннан төзелгән*«Дуслык белән көчле без!»* дип аталган мәктәпкәчә яшьтәге балаларга күпмәдәниятле тәрбия бирү буенча методик кулланмага

# БӘЯЛӘМӘ

Татарстан Республикасының үзенчәлеге булып халкының күпмилләтле һәм күпконфессияле булуы, республика территориясендә яшәүче барлык халык вәкилләренең һәрдаим этномәдәни багланышы һәм гореф-гадәтләренең үзара бәйләнеше тора. Шәвәлиева Г.М тарафыннан төзелгән әлеге методик кулланма нәкъ менә шушы бәйләнешне – күпмәдәниятле тәрбия максатларын истә тотып төзелгән. Чөнки, үз туган ягыңны һәм анда яшәүче башка милләт халыкларын өйрәнү – болар барысы да үз Ватаныңа мәхәббәт тойгыларын ныгыталар, аны тагын да эчтәлеклерәк һәм тирәнрәк итәләр. Иртәрәк өйрәнә башласаң – тирән һәм яхшырак беләсең, яхшырак белгән һәм яраткан нәрсәнең кадерен күбрәк тоясың. Балага үз туган ягында яшәгән халыкларның мәдәниятен, аларның милли киемнәре, милли ашлары, гореф-гадәтләрен өйрәтү – баланың төрле яктан үсүенә йогынты ясый. Бу методик кулланманы мәдәниятара багланышларны ныгыту максатында, татар балаларын башка милләтләрнең мәдәнияте белән таныштырганда файдаланырга мөмкин. Ул, Туган республикабызда гомер итүче башка милләт халыкларына карата балаларда ихтирамлы мөнәсәбәт тудыруда, ихтирамлылык, кешелеклелек, тату яшәү һ. б. шундый матур әхлакый сыйфатлар тәрбияләүдә ярдәмче булыр. Чөнки әлеге халыкларның тарихи һәм икътисадый үсешләрендә күп кенә уртаклыкларга ия булган кебек, аларның килеп чыгышлары, мәдәниятләре, көнкүрешләрендә дә уртаклыклары күп.

Нәтиҗә ясап әйткәндә,«Арча шәһәренең гомуми үсеш бирү төрендәге 6 нчы номерлы «Сандугач» балалар бакчасы» ның татар теленә өйрәтү тәрбиячесе Шәвәлиева Гөлнара Мөбәрәкҗан кызы тарафыннан төзелгән «Дуслык белән көчле без!» дип аталган мәктәпкәчә яшьтәге балаларга күпмәдәниятле тәрбия бирү буенча методик кулланма балалар бакчалары тәрбиячеләре өчен өстәл әсбабы булыр, балалар бакчасында белем һәм тәрбия юнәлешендә үтемле эш алып барырга ярдәм итәр дип уйлыйбыз.

**Рецензент:** Төхфәтуллина Ә.Г.- Габдулла Тукай исемендәге Арча педагогия көллиятенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы, филология фәннәре кандидаты

**ЭЧТӘЛЕК**

1. Аңлатма язуы........................................................................................ 4
2. I бүлек. Һәр милләтнең үз йөзе, мәдәнияте, үз тарихы һәм килеп чыгышы........................................................................................ 5
3. II бүлек. Тәрбия чарасы буларак йола бәйрәмнәре........................... 20
4. III бүлек. Дуслык һәм бердәмлек хисләре үстерүдә халык уеннары........................................................................................ 29
5. IV бүлек. Балаларны уйланырга, фикер йөртергә өйрәтү чарасы буларак- дидактик уеннар.................................................................. 36
6. V бүлек. Әхлак тәрбиясе җирүнең бер юнәлеше - халык әкиятләре ........................................................................................ 39
7. VI бүлек. Балалар өчен бәйрәм иртәләре........................................... 50
8. Кулланылган әдәбият ...................................................................... 70


**Аңлатма язуы**

Һәрбер кеше үз халкының мәдәни мирасын, традицияләрен, гореф-гадәтләрен белергә, алар нигезендә алга таба үсәргә хаклы. Ләкин бугенге көн кешесенә үз халкы кысаларына гына бикләнү бик аз. Әле бит башка халыклар бар. Алар белгәнне дә беләсе килә: аларның казанышларын тормышта кулланасы, җырларын җырлыйсы, биюләрен биисе, уеннарын уйныйсы, төрле милли ризыклар пешерәсе һ.б.лар..

Аралашу җиңел булсын өчен замандашыбызга кимендә 3-4 тел белү кирәк. Мондый омтылыш баланың күзаллавын үстереп кенә калмый, аңарга рухи үсәргә, толерантлык, патриотизм рухында тәрбияләнергә ярдәм итә. Үз халкының мәдәни байлыгын бала башка халыклар мирасы белән чагыштырып өйрәнә

Татарстан Республикасы - күп милләт яши торган төбәк. Шуңа күрә һәр кеше алдына башка милләт кешеләре белән дус яшәү, гомумкешелек кыйммәтләре, башка халыклар мәдәнияте белән таныштыру, үз милләтеңнең телен, мәдәниятен, милләт традицияләрен саклау һәм үстерү бурычын куела. Үз туган ягында, бер җирлектә бергәләп яши торган башка милләт халыкларының мәдәнияте белән системалы рәвештә балаларны таныштырып килү зарур. Бу тәрбиянең нигезен нәкъ менә балалар бакчасында бирә башлау бик зарур: бала әле кәгазь бите кебек чиста, саф, аның аңы әле юк-барга ышануларны, тыюларны белми. Димәк бала, балалар бакчасында милли тәрбия генә түгел, күп мәдәниятле тәрбия дә алырга тиеш.

Күпмәдәниятле тәрбия бирү- балаларны этник, гомуммилли мәдәният белән тирәнтен таныштыру, күп мәдәниятле поли-этник мохиттә яшәргә әзерләү һәм өйрәтү ул.



# I бүлек

## Һәр милләтнең үз йөзе, мәдәнияте,  үз тарихы һәм килеп чыгышы

# ТАТАР ХАЛКЫ

**Килеп чыгышы**. Татар халкы тамырлары ерак гасырларга барып тоташа торган бай матди һәм рухи мәдәнияткә ия. Безнең халык үзенең күп гасырлы әдәбияте, сәнгате һәм мәдәниятенең башка тармаклары тарихы белән хаклы рәвештә горурлана ала. Хәзерге вакытта татарлар – РФнең иң шәһәрләшкән халыкларының берсе. Татарларның шәһәрләшүе шәһәр торулыклары челтәре үсеш алган Идел буе Болгар дәүләте һәм Алтын Урда чорларында башлана. Татарларның төп этник төркемнәре: Идел буе – Урал алды татарлары, Себер татарлары, Әстерхан татарлары.

**Сөйләм телләре.** Татарларның күп гасырлар дәвамында формалашкан халык-сөйләм теле төрки телләрнең болгар-кыпчак төркеменә карый. Татар теле 3 диалектны: көнбатыш (мишәр диалекты), урта диалектны (Казан татарлары) һәм көнчыгыш диалектны (Себер татарлары) үз эченә ала.

**Милли киемнәре.** Хатын-кыз күлмәкләрен озын җиңле, утыртма якалы итеп теккәннәр, итәкләрен бала итәкләр белән, күкрәк өлешен аппликация, күкрәк бизәме (изү) белән бизәгәннәр. Башта сызыклы-геометрик бизәкләр өстенлек итә, әкренләп алар чәчәк-үсемлек бизәкләре белән алыштырыла. Күлмәк өстеннән гадәттә камзул кияләр. Ул кыска яисә озын җиңле, яки җиңсез, туры яки билләп тегелгән, бизәкле, ешрак бер төстәге бәрхет тукымадан тегелгән, кырый капламалары һәм аскы өлешләре укалы тасма, мех белән каймаланган булырга мөмкин. Алъяпкыч, татар хатын-кызлар киеме буларак, аерым урын алып тора. Татар хатын-кызларының алъяпкычлары канатлы булган. Аның күкрәк һәм итәк өлешләрен чиккәннәр.

Борынгы бабаларыбыз Идел буе болгарлары сафьян дип йөртелә торган йомшак күннән затлы читекләр теккәннәр. Халкыбызның бизәкләп чигелгән сафьян читекләре үткән гасырда ук дөнья базарында дан тоткан. Элек-электән килгән бу мактаулы һөнәрне Арча милли аяк киемнәре җитештерү берләшмәсендә эшләделәр. Бу аяк киемнәре чит илләргә чыгарылган. Франция, Англия, Германия, Бельгия хатын – кызлары аларны яратып кигән. Хәзер бу фабрика ябылды. Айрат Солтанов җитәкчелегендә 10 кеше читек тегү һәм чигүне дәвам итә.

Баш киемнәре - калфак, кашпау, өрпәк, яулыклар кулланылышта булган. Калфакны йон тукымадан эшләгәннәр һәм ул чигелгән дә, ә соңрак калфакларны бәрхет, ефәк тукымалардан теккәннәр, затлы җепләр белән чигеп, яки сәйләннәр белән бизәп эшләгәннәр. Салып куела торган бизәнү әйберләре хатын-кыз киеменә өстәмә күркәмлек бирә: кыйммәтле ташлар, металлардан һәм пыяладан тезелгән муенсалар, беләзекләр, алкалар,

йөзекләр, муен-күкрәк (яка чылбыры), күкрәк (изү) һәм чәч толымы (чулпы) бизәмәләре, көмеш тәңкәле асма бизәкләр.

Ирләр киеме шулай ук иркен һәм озын (тезгә җиткән) күлмәктән, һәм җиңел киҗе-мамык тукымалардан тегелгән ыштаннан гыйбарәт була. Күлмәк өстеннән камзул яки казаки, киселеше, озынлыгы, яка формасы һ.б. белән аерылып торган, җилбәгәй киелә торган өске киемнең төрле төрләре киелгән.

Ирләрнең баш киеме- түбәтәй – төрки халыкларының бик киң таралган һәм бүгенге көнгә кадәр абруен югалтмаган баш киеме. Түбәтәйне бәрхеттән тегәләр, ефәк җепләр белән чигеп яки сәйләннәр белән бик матур итеп бизәп куялар. Түбәтәй орнаментлары күпчелек лалә чәчәге, ромашка, дәлия, пион, кыңгырау, канәфер, тукранбаш чәчәкләрен һәм яфракларын хәтерләтә. Әрсезгә кия торган түбәтәйләрне карарак төстәге тукымадан, ә бәйрәмнәрдә кию өчен затлырак тукымадан (ефәк, бәрхет, парча) эшләгәннәр. Байлар, сәүдәгәрләр энҗеле яки алтын-көмеш җепләр, укалар, канитель белән чигелгән түбәтәй киюне дәрәҗәле санаган. Борынгырак заманда түбәтәйләр бераз очлырак булса, аннан соңрак түбәтәйләр башка ятып тора торган яссырак форма ала. Шәһәр зыялылары арасында кара хәтфәдән эшләнгән яссы түбәле түбәтәй - кәләпүшләр тарала. Ирләр аяк киеме күн һәм киез итекләрнең төрле төрләре, башмаклар, тула оеклар, чолгаулар, аякчулар һ.б.дан тора, еш кына алар төрле төстә һәм бизәкле була.

**Милли аш-сулары.** Татар аш-суының үзенчәлеге – аның камыр ризыкларына гаять бай булуы. Арыш һәм бодай ипиен түгәрәк яисә озынча зур ипи савытларында ачы камырдан пешергәннәр. Чүпрәле яисә төче камырдан көлчә, кабартма, күмәч, белен, коймак, пәрәмәч, өчпочмак, бәлеш, бөккән, гөбәдия, сумса, кыстыбый ясаганнар һәм чәй ашларыннан төче камырдан кайнап торган майда кыздырып борынгыдан ук килгән милли ашлар –.чәк-чәк, бавырсак, кош теле, юка һ.б. әзерләгәннәр.

Чәй эчү аерым популярлык казанган. Элек-электән күпчелек авыл кешеләре чәй урынына мәтрүшкә, бөтнек, сары мәтрүшкә, гөлҗимеш, карлыган, кура җиләге яфраклары һәм җимешләре, юкә чәчәге һ.б. җирле үләннәрне пешереп эчкәннәр. Татарлар тары, карабодай, борай, солы, арпа, бодай ярмаларыннан әзерләнгән боткалар ашаганнар, яңа чалынган терлек ите (сарык, сыер, ат, йорт кошлары) кулланып аш пешергәннәр, ә җәй көне балтырган, кузгалак һ.б. үсемлек яфракларыннан да аш пешергәннәр. Бәрәңге, кабактан әзерләнгән ризыклар киң кулланылган.

Безнең милләт вәкилләре бөтен дөньяга сибелгән. Дөньяда 12 миллионга якын татар яши. Рәсәйдә яшәүче милләтләр арасында халык саны буенча икенче урынны татарлар алып тора: 5 миллион 500 мең тирәсе тәшкил итәләр. Татарстанда исә 2 миллионнан артык татар милләте кеше гомер кичерә.

# РУС ХАЛКЫ

**Килеп чыгышы.** Борынгы рус дәүләте җирлегендә XIII–XV йөзләрдә 3 төркемгә бүленгән бердәм этносәяси берлек оеша (белоруслар, украиннар һәм руслар) Төрле этник процесслар нәтиҗәсендә русларның төньяк, көньяк һәм урта (урта рус) этнотерриториаль төркемнәре барлыкка килә. Идел буендагы рус халкы урта төркемнең үзенчәлекле астөркеме булып тора. Татарстанда рус авыллары, Чулман алды һәм Чулман аръягының эчкәре районнарында да, татар, чуаш, мордва авыллары янәшәсендә дә корыла. Алар, «рус» сыйфатламасы өстәлеп, еш кына күршедәге рус булмаган халык яшәгән авыл исемен алалар: Рус Янтыгы, Рус Әхмәте, Рус Исламы һ.б. руслар, башлыча, илнең төньяк, үзәк һәм Югары Идел төбәкләреннән күчеп утыралар.

**Сөйләм телләре.** Туган телләре – кириллицаның бер вариантыннан гыйбарәт алфавитлы рус теле.

**Шөгыльләре.** Рус халкының төп шөгыле игенчелек була. Хуҗалыкта тимерчелек, балыкчылык, бакчачылык, йорт кәсепләре зур роль уйный. Руслар элек электән олаучылык, бигрәк тә ерак араларга йөкләр ташу белән шөгыльләнәләр. Казан губернасының төньяк районнарында урман кәсепләре – урман кисү, сумала һәм дегет куу, күмер яндыру һ.б. киң таралган булган.

Рус халкы элек-электән челтәр бәйләү белән шөгыльләнгән. Россиянең төньяк-көнбатыш өлкәләреннән күченүчеләр белән бу сәнгать бергә килә, әмма аерым төбәкләрдә генә үсеш ала. Шулай ук рус халык сәнгатенең агачка уеп бизәк ясау төре популярлык казанган. Ул аеруча өч кырлы уелмалы техникада, интерьер элементларында, йорт кирәк-яракларында, савыт-саба, эш коралларында еш очрый. Орнаментта гади һәм өермәле түгәрәкләр, яфраксыман бизәк мотивлары өстенлек ала. Борынгы заманнарда капка баганалары, өй кыеклары шул рәвешле бизәлгән, түбә җепсәсенә стильләштерелгән ат башы яки кош сурәтләре беркетелгән дип фаразлана.

Хәзерге вакытта рус халык сәнгате традицияләре йортларга уеп бизәк төшерү, нәфис тукучылык чигү төрләрендә үсеш ала. Рус халкы арасында иҗади мөмкинлекләрне тормышка ашыру ихтыяҗы югары дәрәҗәдә саклана. Шәһәрләрдә һәм авыл җирләрендә төрле күргәзмәләр оештырылып тора.

**Милли киемнәре.** Рус хатын-кыз киемен ике төргә бүлергә була. Беренчесе − сарафанлы, икенчесе – понёвалы (итәкле). Сарафанлы кием күбрәк киелгән. Хатын-кызның күлмәге «рубаха» дип йөртелгән. Аны җитен тукымадан теккәннәр. Рубаханың җиңнәре, якасы, итәге чигелгән, төймәләр, ялтыравыклар белән бизәлгән булган. Күлмәк өстеннән сарафан кияргә яраткан рус халкы. Ә сарафан өстеннән нык, тыгыз тукымадан яки бәрхеттән тегелгән сырган кофта (душагрейка) кигәннәр. Яки сарафан

өстеннән билләренә яки култык асларыннан запон – озын алъяпкыч та бәйләгәннәр. Костюмның икенче төре – понёвалы, ягъни сарафан урынына путалы итәк киелгән.

Рус халкында хатын-кызларның баш киеменә аерым игътибар биргәннәр. Кызлар башларына тасма, бәйләвеч кисә, кияүгә чыккан хатын-кызлар, чәчләрен каплап, кокошник кигәннәр. Йорт тирәсендә исә яулык япканнар. Киемне муенсалар, беләзекләр белән бизәгәннәр.

Элек авылларда яшәүче руслар, бигрәк тә ярлы крәстияннәр арасында, чабата төп аяк киеме була, аларны җәенке башлы, биек кырыйлы итеп кыйгачламыйча курыстан үрәләр. Җәен чабатаны – киндер, кышын постау чолгаулар (ыштырлар) белән кияләр, бау белән бәйлиләр. Шулай ук «табаннар» («ступни», галош рәвешендә үрелгән аяк киеме) киеп йөриләр. Көннән яисә бәрхеттән тегелгән башмак яки итекне бәйрәмнәрдә генә кигәннәр. Шәһәр тирәсендә яшәүчеләр аягына гел күн итек киеп йөргәннәр.

Ир-атлар йон, җитен һәм киндер тукымалардан туника рәвешендә тегелгән кыек якалы күлмәкне чалбар эченә кыстырмыйча кияләр, билбау пута буалар. Өске киемнәрдән сырма, кафтан, чикмән, әрмәкләр (сарык йонынннан кафтаннар), толып, туннар кигәннәр. аш киемнәре төрле – түгәрәкләнгән очлы конус сыман киез калфак, цилиндр рәвешле эшләпәләр булган.

**Милли аш-сулары**. Щи, уха, рассольник, окрошка, пилмән, белен. Русларга аш-су әзерләүдә киң ассортимент продуктлар куллану, төрле ысуллар хас. Икмәк, камыр һәм ярма ризыклары, яшелчәләрдән бәрәңге, кәбестә, кыяр өстенлек итә. Җиләк җимешне крәстияннәр җимеш бакчалары күп булган кайбер җирләрдә генә, башлыча, Идел алды төбәгендә кулланганнар.

Азык-төлек сыйфатында һәм дәвалау максатында үсемлекләр һәм үләннәр: кычыткан, алабута, кузгалак, сәрдә, балтырган, әрекмән тамыры һ файдаланылган. Алардан сыек ризыклар әзерләгәннәр, төелгән орлыкларын икмәк пешергәндә онга өстәгәннәр. Шулай ук гөмбәләр: ак гөмбә, баллы гөмбә, усак гөмбәсе, каен гөмбәсе кулланылган. Аларны кыздырганнар, тозлаганнар, киптергәннәр, гөмбә ашы пешергәннәр. Русларда икмәк квасы, кесәл, соңрак чәй традицион эчемлек булып исәпләнгән.

Халык саны буенча дөньяда рус милләте 130 миллионнан артык дип исәпләнә. Рәсәйдә 112 миллион чамасы рус яши. Татарстанда 1 миллион 500 тирәсе рус милләте халкы гомер итә. Русларның зур күпчелеге Татарстан Республикасы шәһәрләрендә – башлыча, Казанда һәм якын тирәдәге районнарда, шулай ук Идел, Кама һәм Вятка елгалары үзәннәре тирәсендәге җирләрдә яши.

# УДМУРТ ХАЛКЫ

**Килеп чыгышы.** Борынгы удмурт халкы, Идел буена килеп урнашкан ыругларддан килеп чыккан дип санала. Удмуртлар тамырда борынгы төньяк һәм урта Урал һәм Җаек буе (Кама) халкы. Удмуртлар үзләре беренчел аңлатманы «көчле кеше» дип тәрҗемә итәләр, икенче атаманы “чит, оч, кырый кешесе” дип тә атыйлар. Борынгы чорларда удмурт авыллары тезелеп киткән чишмәләр һәм елга ярында урнашкан. Алар авылларга ошамаган да булган, ярым күчмә тормыш алып барганнар. Чын авыллар 19 гасырда гына барлыкка килә башлаган. Йортлары агач корылмалар булган.

**Сөйләм телләре.** Удмуртларның телләре исә (аларны ар дип тә атаганнар) фин-угыр телләре группасына карый. Аларда басым һәрвакыт сүз ахырында, әлифбалары рус графикасына нигезләнеп барлыкка килгән. Антропологик типлары буенча алар субурал тибына якын, ягъни европа һәм монгол группалары катнашы нәтиҗәсендә барлыкка килгән тип.

**Шөгыльләре.** Удмуртлар тырыш халык булып, аучылык, җир эшкәртү, балыкчылык белән шөгыльләнгәннәр. Хәзер инде халыкның төп массасын эшчеләр һәм интеллигенция тәшкил итә.

Ирләр иген иккән, аучылык, терлекчелек, умартачылык белән шөгыльләнгән, хатын-кызлар тукыган, чиккән, бәйләгән һәм барлык кием кулд

**Милли киемнәре.** Удмурт милли киемнәре гади түгел, ә үзләренә җәлеп итүче. Өстәвенә, удмуртларның киемнәре кайда яшәүләренә карап төрле-төрле булган. Хатын-кызларның берләре (төньяк удмуртлар) озын җиңле, ачык изүле ак күлмәк (дэрем), аның өстеннән тәңкәле, укалы күкрәкчә (чыртывесь, чыртыкыш, уксе тирлык), күкрәксез алъяпкыч (азькышет), аларга өстәмә кыска җиңле камзул (саестэм) кышын йон кафтан (зыбын, дукес, сукман) кисә, икенче төбәктә (көньяк удмурт ) яшәүчеләр өчен ак кием дини бәйрәм киеме булып саналган.

Аларның милли күлмәкләре җете төсле, бизәкле һәм төрле тукымалардан теркәп ясалган биек якалы булган. Удмурт киемнәрендә ромб, квадрат, өчпочмак, йолдыз формалары бизәк буларак еш кулланыла. Аның өстеннән изүле, күкрәкле тәңкәле алъяпкыч (кабачи), йон кофталар, халат (шортдэрем) кигәннәр. Алъяпкычның путасы саклаучы көч дигән ышану булган. Начар көчләрне куу өчен пута очына һәм алъяпкыч итәгенә чылтырап торучы тәңкәләр теккәннәр. Хатын-кызлар бәйрәмнәргә озын, бизәкләп бәйләнгән, чигелгән оеклар (пыдвыл)

яки оекбашлар(чуглэс) киеп, чабата (кут), башмак (ката) яки итекләр (гын сапег) кигәннәр.

Башларына маңгай капланып тора торган «йыркерттэт», сөлге формасындагы косынка «чалмы», кияләр, алар тәңкәләр, укалар белән бизәлеп эшләнгән. Бу баш киеме рус кызларының баш киеме - кокошнигын хәтерләткән. Яшь кызлар тәңкәле тәкыя бәйләгән. Аның өстеннән яулык ябылган яки чигүле япма «сюлыкош» кулланылган.

Ирләрнең өс киемнәре, күлмәк бизәкләре хатын-кызларныкыннан аерылмаган. Күлмәк якалары бизәкләр белән чигелеп, кырыйдан төймәләнеп, басып тора. Ирләр күлмәге саклаучы көче булган пута белән тулыландырылган. Камзул сыман җәйге киемнәре «зыбын», кышкы йоннан тукылганы «дукес», туннары «пась» дип аталган. Киң балаклы чалбарлары, җете төсләрдән (күп вакыт куе зәңгәр) тегелгән, ак сызык сызылган. Башларында сарык йонынннан бәйләнгән башлыклар яки эшләпә булган, аякларына чабата, итек, башмаклар кигәннәр.

**Милли аш-сулары.** Төп ризыклары булып хайван итләре һәм үсемлекләр торган. Урманнардан гөмбә, җиләк, үләннәр җыйганнар, бакчада үстерелгән кәбестә, шалкан, керән, бәрәңге киң кулланылыш алган. Иң яраткан ризыклары булып төрле эчлекле (творг, ит, бәрәңге, кәбестә) пилмән, төрле ярмалы, кәбестәле ашлар санала. Салкын окрошка, шалкан ашын аеруча яратканнар. Төрле квас, морсларны еш кулланганнар.

Удмуртларның мәдәнияте күбрәк авыл хуҗалыгы белән бәйләнгән. Алар бәйрәмнәрне югары көчләргә табыну, аларга корбан китерү белән башлап җибәреп, соңыннан уеннар, күмәк җырлы-биюләр белән дәвам иткән.

19 гасырдан соң провославие динен кабул иткәч чиркәү бәйрәмнәре, дини бәйрәмнәр удмуртларның тормышын үзгәртеп җибәрә. Аларның Раштуа, Чукындыру, Пасха һ.б. бәйрәмнәр икенчерәк төс ала. Бүгенге көндә дә удмуртлар, праваславие динендә булсалар да, бәйрәмнәрендә борынгы христиан диненең кайбер элементларын кулланалар.

Хәзерге вакытта Татарстан республикасының җиде районында (Кукмара, Мамадыш, Арча, Балтач, Әтнә, Биектау) 25000 удмурт кешесе яши. Язгы чәчүдән соң татар халкы “Сабантуй” бәйрәме уздырса, удмуртлар «Гырон быдтон» ны бәйрәм итә.

# БАШКОРТ ХАЛКЫ

**Килеп чыгышы.** Башкортларның борынгы бабалары булып төркиләр халыклар санала. Урал тауларының башланган урыннарына, тау итәкләренә, Идел, Чулман (Кама) елгалары килеп урнашып, көтү көтеп ярым күчмә яшәү рәвеше алап барганнар. Алар җәйләрен далалаларда урнашкан тирмәләрдә (Юрта дип атаганнар) көтү көтеп, иген иккәннәр, кышлау өчен урман эчендә авыллары булган. Анда кызыл балчыктан измә изеп, бүрәнәләрне сылап йортлар (бурама) төзеп кышлаганнар, ул йортлар ярым җир астында булган (землянка). Бу йортларның алачыклары булган, шунда аш әзерләнгән. Башкортлар элек электән ярым күчмә тормыш рәвеше алып барганнар, һәм бу яшәеш аларның үзенчәлекле гореф-гадәтләрендә дә, ашау-эчүләрендә дә ачык чагылган.

Башкортлар, физик төсмерләре буенча татарлардан аерылмыйлар дияргә мөмкин. Әмма монгол йөзле, кысык күзле, чыгып торган яңаклы башкортлар да булган. Буйлары озын түгел, әмма алар көчле.

Башкортлар Идел буе халыкларына шартлы рәвештә кертелгәннәр. Дөреслектә алар Урта Азия һәм Идел буе халыклары арасында урта урынны алып торалар һәм мәдәни яктан ике якка да якын.

**Сөйләм телләре**. Башкорт теле татар теленә бик охшаган. Татар белән башкорт күрешсә, алар бер-берсенең сөйләмен аңлыйлар.Башкорт телендәге кайбер сүзләрнең мәгънәсе бераз аерыла. Башкортлар борынны- “танау”, тезне- “тубык” ди. Башкортта әни- “әсәй”, әти- “атай”, бабай- “олтай”, әби- “өләсәй” була.

**Шөгыльләре-** терлекчелек, малчылык булган. Аларның сарык(куй), сыер кебек терлекләрдән кала зур гына ат көтүлекләре дә булган. Аучылык, урман эше, балыкчылык, умартачылык та башкорт халкы белгән кәсепләр саналган. Күбрәк алтын приискаларында эшләгәннәр: утын кискәннәр, күмер әзерләгәннәр, руда ташыганнар һ.б. Чисталык һәм пөхтәлекләрен истә тотып, башкортларга алтын юу эше дә йөкләнә торган булган.

**Милли киемнәре.** Традицион башкорт киеме- кешенең кайсы милләттән икәнен ачык күрсәтеп тора. Башкортларның күчмә халык икәнен, малчылык белән шөгыльләнгәнен күрсәтеп, төрле тукымалардан, сарык тиреләренән тегелгән аларның киемнәре. Аларда күбрәк кызыл, яшел, күк, кара төсләрне кулланганнар.

Хатын-кызларның өстендә билле, бала итәкле озын күлмәк, аның астыннан, башка төрки халыкларныкы кебек үк, ыштан булган. Күлмәк өстеннән төрле укалар, тәңкәләр белән бизәлгән, чигелгән камзул кигәннәр. Камзулларның озын җиңле халат сыманнары да булган. Алар

гадәттә бәрхет тукымалардан тегелеп, башкортларның яраткан төсләре белән укалап чигелгән. Муеннарына, түшләренә тәңкәләр, мәрҗәннәр белән бизәлгән күкрәкчә-түшлекләр бәйләгәннәр. Кияүдә булганнар, кошмау(яулык) япканнар, яшь кызлар башларына тәңкәләр тезеп бизәлгән тәкыя бәйләгәннәр. Кыш көне чикмән, тун, толып киеп йөргәннәр. Бәйрәм киемнәре чылтыраучы тәңкәләр, елтырап торган укалар белән бизәлгән. Аякларына күн итек, башмак, туфли, күн галошлар киеп йөргәннәр. Бәйрәмдә кия торган оекларын төрле төстә тегеп бизәгәннәр. Малчылык белән шөгыльләнүче халыкның барлык кешеләре дә, ярлы, бай булуына карамастан, күн аяк киеме кигән.

Хатын-кыз киеме кечкенә вакыттан ук кыз баланы, күз тиүдән сакларга тиеш булган. Шунлыктан, киемен тәңкә, чук, мәрҗән белән бизәгәннәр. Яше дә тулмаган кыз балаларның да күлмәкләренә, баш киемнәренә тәңкәләр тегелгән. Кызларның чәч бизәүләре бик күп төрле булган.

Башкортлар ирләре нигездә – күлмәк һәм бик киң булмаган ыштан, камзул яки кафтан кигәннәр. Кыш көннәрендә сарык тиресеннән тегелгән тун яки толып кигәннәр, билләрен каеш белән буганнар. Көндәлек баш киеме - түбәтәй - өлкәннәрнеке кара, яшьләрнеке яшел, кызыл, күк төсле, алар ука, чигү җепләре белән бизәлгән.

Шулай ук кием – яшь аермасы билгеләрен, гаилә хәлен, дәрәҗәсен дә чагылдырган.

**Милли аш-сулары.** Башкортлар бик кунакчыл халык, кунакларга тәгъдим ителә торган сый – атаклы башкорт балы белән сөтле кайнар чәй. Эссе җәйдә ат сөтеннән ясалган кымыз, әйрән аларның төп эчемлеге . Ашамлыклардан – ат яки сарык итеннән пешкән бишбармак, токмач, палма, куллама, итле аш , аерым савытта, шулпа белән бирелә торган казы (өйдә ясалган, киптерелгән колбаса) иң атаклылыардан санала. Төче камырдан – җәймә, көлчә пешерәләр. Шулай ук бавырсак, чәк-чәк, алар табыны ризыклары.

**Башкорт халык музыка уен кораллары**: курай, кубыз, думбыра.

Башкортлар бүгенге көндә Татарстанның Әгерҗе, Азнакай, Актаныш, Баулы, Әлмәт, Алабуга, Минзәлә, Сарман, Мөслим, Лениногорск, Менделеевск, Тукай, Ютазы районнарында башкортлар төпләнеп яши.

# МАРИ ХАЛКЫ

**Килеп чыгышы.** Мари (чирмеш) теле – фин-угыр телләре төркеменә керә. Өч төркеме аерыла: Болын чирмешләре, Тау чирмешләре һәм Көнчыгыш чирмешләр. Тау марилары Иделнең уң як ярында, Болын чирмешләре Идел-Урал, Көнчыгыш – Башкортстан һәм Урал территорияләрендә яши. Марилар мари телендә сөйләшәләр, язулары – рус алфавиты нигезендә.

Марилар элек-электән елга-ерым буйларында таралып яшиләр. Аларда зур булмаган моногамик гаиләләр өстенлек итә, әмма бүленеп чыкмаган, 3–4 буын якын туганнарны берләштергән зур гаиләләр дә була. Тораклары – ике бүлемле (өй-өйалды) яки өч бүлемле (өй-өйалды-өй һәм руслардан кергән өй-өйалды-келәт), ике яклы түбәле буралган йорт. Мари төбәгенең төньягында һәм көнбатышында рус традицияләре йогынтысында бүлеп лынган аш-су әзерләү урыны, рус миче һәм сәндерәләре булган йортлар өстенлек итә. Көнчыгышта, бигрәк тә Кама алдында, мари өенең эчке күренеше татар интерьерын хәтерләтә – казаны сылапябыштырылган мич, түр дивар буенда киң сәке, бүлеп алу өчен чаршаулар элү һ.б. Гадәти утар корылмаларына амбар яки еш кына ике катлы, икенче катында галерея булган бина рәвешендәге келәт, баз, сарай керә. Бай утарларда әвенле ындыр табагы да була. Җәйге чорда файдаланыла торган торак-кухня (кудо) борынгы корылма булып исәпләнә – ул җир идәнле, түшәмсез итеп җиңелчә бурадан эшләнә; казан асылган ачык учактан төтен чыксын өчен түбәсе ярык калдырып ябыла. Элекке вакытта кудо шулай ук гаилә-нәсәп вәкилләренең җыелып гыйбадәт кылу һәм йолалар башкару урыны булып та хезмәт иткән. Мунча, гадәттә, ындыр артында, су чыганагына якынрак җирдә салынган.

**Шөгыльләре** – сөрүле игенчелек. Туфрак сука (шогавуй), сабан (агавуй, сабан), тырма (тырма, шүре), китмән (кәтмән) белән эшкәртелә. Төп басу культуралары – арыш, солы, арпа, тары, карабодай, бәрәңге; техник культуралар – киндер, җитен, колмак; яшелчәләр – суган, кәбестә, торма, кишер. XIX йөздә тау ягы мариларында бакчачылык үсеш ала. Марилар атлар, мөгезле эре терлек, сарыклар, йорт кошлары асрыйлар; дуңгыз һәм кәҗәләр сирәк очрый, чөнки алар «хәрам», корбанга яраксыз санала. Сунарчылык, балыкчылык, умартачылык, кыргый җиләк-җимеш, гөмбә җыю икенчел роль уйный. Агач, үсемлек сүсе, йон, күн эшкәртү белән бәйле кәсепләр (күмер яндыру, сумала кайнату, кап сугу, үрелгән әйберләр җитештерү һ.б.) шәхси хуҗалыкта әһәмиятле санала, әмма капиталистик мөнәсәбәтләр үсеше чорында аларның продукциясе инде

товар булып китә. Үсешкә ирешкән сәнгать һөнәрләре: зәргәрчелек (көмештән хатын-кыз бизәнү әйберләре эшләү), агачны кисеп бизәкләү, тукучылык, чигү.

**Милли киемнәре.** Кием элементлары түбәндәгеләрдән гыйбарәт: туника сыман өлгеле күлмәк (тувыр), ыштан (йолаш), туры арттакталы ачык чабулы яисә кисеп бөрмәләнгән кафтан (шовыр), алъяпкыч (ончылсакыш), бил тастымалы (солык), пута (юштә). Көнчыгыш мари хатын-кызларында төрки халыклар үрнәгендәге чуар күлмәк кия. Көндәлек киемнәрне дә тегеп, чигеп, аппликация юлы белән бизәклиләр, әмма бәйрәм һәм туй киемнәре аеруча купшы бизәлә. Аларга өстәмә рәвештә күпсанлы зәркән бизәмәләр кулланыла – бил, күкрәк, муен, колак бизәмәләре сәйләннәрдән, кабырчык, ялтыравык, тәңкәләрдән эшләнә, шулай ук төрле көмеш беләзек һәм йөзекләр кию гадәте яшәп килә. Кияүдәге хатын-кыз баш киеменең 3 төре киң таралган була: баш чүмеченә куела торган яссы калаклы конус рәвешендәге калфак (шымакш), баш сөлгесе (шарпан), руслардан кергән каты өсле турыпочмаклы тәкыя (сорока). Шурка – мордва һәм удмурт хатын-кызларыныкы кебек үк, каен тузыннан ясалган борынгы биек баш киеме. Өске кием булып ак яисә кара постаудан туры итеп һәм киселеп, бөрмәләп тегелгән кафтаннар (мыжер), кайры һәм манылган киндер яки фабрикада эшләнгән Аяк киеме – чабата (йындал), күн итек (кем), киез итек (межгем). Мари хатын-кызларында элек-электән аяк балтырларын кара постау ыштырлар белән чолгап кую гадәте яшәп килгән, шуңа күрә күрше татарлар аларны «кара аяклар» дигәннәр.

**Милли аш-сулары.** Традицион ризыклары – чумарлы аш (лашка), ит яки эремчек пилмәне (подкогыльо), ит, терлек мае яки каннан ярма кушып пешереп әзерләнгән казылык (сокта), какланган ат казылыгы (каж), катлы белен (команмелна), көлчә (эгерче), төче солы икмәге (шергинде). Мариларга гына хас кайбер ашларны әзерләгәндә тиен, керпе, тузбаш, зәһәр елан ите, балык оны, киндер орлыгы кулланылган. Карчыга, байгыш кебек киек кошлар итеннән аерым ризыклар әзерләнгән, шул ук вакытта кыр казлары, торна, аккош һәм күгәрченнәрне аулау тыелган.

Татарстан Республикасында – 18 848 мари яши дип исәпләнә. Күбрәк Әгерҗе, Актаныш, Алабуга, Кукмара, Менделеевск, Минзәлә, Мөс лим районнарында гомер итәләр.

# МОРДВА ХАЛКЫ

**Килеп чыгышы.** Мордваларның бабалары – фин-угор кабиләләре. Озак вакытлар дәвамында мордвалар төрки халыклар һәм Борынгы Русь белән багланышта яшәгәннәр. Мордва халкын ике субэтник төркемгә бүләләр: эрзя һәм мокша.

Элек мордваларда традицион торулыклар – урамлап төзелгән авыллар һәм салалар була. Торaклары, гадәттә, ике яки өч өлешкә бүленгән урта-рус планировкалы өйләрдән, мукшыларда кайчак көньяк-рус планировкалы өйләрнең көнбатыш тöреннән гыйбарәт була.

Мордвалар – дини халык. Әмма ышанулары үзенчәлекле, чөнки алар бер Аллага һәм күп төрле христиан изгеләренә ышана. Тугандаш гаиләләр арасында традицион якын мөнәсәбәтләр саклана: бергә гаилә бәйрәмнәре үткәрелә, йорт салганда, уңышны урып-җыйганда һ.б. вакытларда үзара ярдәм күрсәтелә.

**Сөйләм телләре.** Мордва телләренең сөйләм төзелешенә рус теленең йогынтысы зур. Мордва теленә мукшы яки эрзя тибындагы күчемле һәм катнаш сөйләшләр күплеге хас. Эрзялар эрзя телендә, ә мокшалар үзләренең мокша телендә сөйләшә. Эрзя теле – 5 диалектны, мукшы теле 3 диалектны үз эченә ала. Эрзяннарны тагын шокша һәм терюханнар, ә мокшаннарны каратаиларга аералар. Терюханнар Түбән Новгород өлкәсенең Ерак Константиново районында тора, алар туган телләрен белми, үзара русча сөйләшә. Каратаилар республикабызның Кама Тамагы районында яши һәм татарча сөйләшә. Шулай ук Лениногорск районы Мордовская Кармалка авылында эрзяләр гомер кичерәләр. Алар июнь ахырында Шкай Алладан мул уңыш сорап «Веле озномс» дигән җәмәгать бәйрәме дә оештыра. Эрзялар кешеләрне урман җәнлекләреннән килеп чыккан дип уйлый. Шуңа аюдан сәламәтлек сорап махсус гыйбадәтләр уздыралар.

Мокша телендәге бик күп сүзләрнең төрки тамырлары бар. 18 нче гасырда мордва теле кириллица нигезендә булса, аннан соң ул үзгәрә башлый һәм 20 нче гасырның 30 нчы елларында бүгенге хәленә керә.

**Шөгыльләре.** Мордваларның электән килгән төп шөгыле – сөрүле игенчелек (уҗым арышы, борай, тары, җитен, киндер). Терлекчелек (мөгезле эре һәм вак терлек), чолыкчылык (кыргый бал кортларының балын җыю), соңрак умартачылык сизелерлек роль уйный.

**Милли кием.** Элек-электән мордва хатын-кызлары киеменең нигезен сары һәм яшел төс кушып, кызыл, кара, зәңгәр төстәге чигүләр белән мул бизәлгән ак киндер күлмәк (панар) тәшкил итә. Эрзя хатын-кызлары

арасында өслеге тулысынча чигүле йола күлмәге (аны кызлар балигъльк көнендә яки туйда кияләр), ак киндердән тегелгән, ике чабулы, халат рәвешендәге өске кием киң тарала. Мукшы хатын-кызлары балаклары тубыкка җиткән ак киндер ыштан кияләр, аларның киеме металл, сәйлән, тәңкәләр һәм кабырчыклардан эшләнгән төрле бизәмәләр белән тулыландырыла, өске кием – чикмән, туннар.

Мордваларда үзенчәлекле күкрәк бизәмәсе сыйфатында яка каптырмасы кулланыла. Эрзяларда ул – йомылмаган овал, мукшыларда трапеция рәвешендә. Эрзя хатын-кызларының үзенчәлекле янбаш бизәмәсе – мул чигешле, укалар, йон чуклар, металл аеллар куелган пулагай, аны беренче тапкыр балигъльк көнендә кияләр. Хатын-кызлар сүрәкә рәвешендәге, сөлгеләрдән, япмалардан каты өслектә биек итеп эшләнгән төрле баш киемнәре кияләр.

Кызлар арасында сәйлән белән һәм укалап чигелгән маңгай тасмасы таралган. Хатын-кызлар киеменең үзгәртелгән төрләре хәзер дә киелә. Мордвалар элек кыеклап үрелгән чабаталар кигәннәр. Аякларга ак һәм кара чолгаулар ураганнар.

Мордва ир-егетләре ак озын күлмәк “панар” һәм ыштан “понкст” кигән. Киемнәрендә милли бизәкләре геометрик фигуралардан – ромб, өчпочмак, квадратлардан, сызыклардан, сигез очлы розеткалардан тора. Билбау-кушак күннән эшләнгән, тимер, көмеш, бронза белән бизәлгән. Билбауга ату кораллары элә торган булганнар. Башларында киез эшләпә, картуз, аякларында чабата булган, хәзер итек кияләр.

**Милли аш-сулары**. Алар ризыклары игенчелек продуктларыннан әзерләнә: ачы икмәк, төрле эчлекле (күбесенчә боткалы) бәлешләр, бодай, тары, борчак оныннан коймак, токмач, салма. Ит ризыклары: мукшыларда – суган белән кыздырылган ит, эрзяларда – кыздырылган ит һәм тәмләткечләр салынган терлек эч-башлары бәйрәмнәрдә һәм йолалар башкарганда әзерләнгән. Шулай ук мордвалар бодай оныннан «суронь пачалксеть» дип аталган коймаклар, «офтонь лапат» атамалы ит кәтлитләре, «прякат» дип аталучы кәбестә, яшел суган, бәрәңге, яисә боткалы тәмле пироглар пешерәләр.

Рәсәй Федерациясендә барлыгы 744 мең мордвалар исәпләнә. Татарстан Республиксында мордва халкы – 19 156 кеше яши. Алар Чаллы, Әлмәт, Бөгелмә, шәһәрләрендә, Тәтеш районында, Лениногорск районының Мордовская Кармалка авылында гомер кичерәләр.

# ЧУАШ ХАЛКЫ

**Килеп чыгышы.** Чуашарның бабалары - фин-угор һәм төрки кабиләләрне кушылуы нәтиҗәсендә килеп чыккан төрки-болгар кабиләсе дип исәпләнә. Фаразларның берсе буенча, «чуаш» этнонимының тамырлары болгарларга кардәш кабиләләрнең берсе – суарлар атамасына барып тоташа. Торулыкларның төп төрләре – авыллар һәм салалар, елга һәм күл буйларында урнашалар. Хуҗалыкларында матур бизәкле капкалар, каралты-кура белән тоташкан йортлар, бакчаларында кара мунчалар бар.

**Сөйләм телләре**. Туган телләре – чуаш теле. Чуаш теленә татар, гарәп, мари, рус теленнән күп кенә алынмалар кабул ителгән. Чуашларның күбесе православие динендә. Араларында мәҗүсиләр дә бар. Тел буенча чуашларны ике төргә бүләләр: вирьял (верховые) һәм анатри (низовые). Чуаш телендә “матур” сүзенең 50 гә якын синонимы бар. Сәламләшү- татарчага якын. “Исәнмесез”- “салам” була. Саубуллашырга теләсәң, “чибәр” дияргә кирәк. Яратам сүзе- “юрадап” дип әйтелә.

Татарстан башкаласы Казанда, чуаш телендәге беренче газета- “Сувар” чуаш газетасы инде 30 елга якын басылып килә.

**Шөгыльләре.** Чуашларның төп традицион шөгыле – игенчелек: күбесенчә бөртекле культуралар – арыш солы, арпа, тары, борай, сирәгрәк борчак, карабодай, бодай чәчәләр. Азык хәзерләү биләмәләре аз булу сәбәпле, терлекчелек үсеше алга китми. Чуашлар хуҗалыгында бакчачылык, умартачылык, колмак үстерү һәм йорт кәсепләре (чигү, чүлмәкчелек, үрү-бәйләү, тукучылык һ.б.) зур роль уйный. Зур чуаш авылларында кустар-кәсепчелек житештерүе (мичкә, көпчәк ясау, агач эше), бау-аркан ишү, чыпта сугу һ.б. үсеш кичерә.

Элек чуашларның йолалары һәм бәйрәмнәре аларның мәҗүси карашлары белән тыгыз бәйләнгән була һәм хуҗалык-игенчелек календаре белән тәңгәл килә: кояшны олылау бәйрәме (Май чабу), кояшка, һәм бабаларга корбан чалулы күпкөнлек язгы бәйрәм (Манкун), язгы җир сөрү бәйрәме (Акатуй) һ.б. Ашлыкларны җыеп алгач, яңа уңыш хөрмәтенә рәхмәт белдерүләр йоласы башкарыла. Ел дәвамында, бигрәк тә язгы-кышкы айларда, яшьләр арасында күңел ачулар, тамаша кылулар оештырыла.

**Милли киемнәре.** Чуашларның традицион киемнәре милли үзенчәлекләре белән аерылып тора. Хатын-кызлар киеменең нигезен туника рәвешендәге күлмәк (кепе) тәшкил итә, тау ягы чуашлары һәм болын ягы чуашлары – өйдә тукылган юка ак тукымадан тегелгән кепеләр, ә түбән як чуашлары башта аска таба киңәеп киткән ак, соңрак чуар тукымадан бөрмәләп

тегелгән күлмәкләр киеп йөргәннәр. Аларны чигелгән, аппликациялəп бизәлгән алъяпкыч һәм күкрәкчә белән кигәннәр. Хатын-кызлар киемен көмеш һәм бакыр акчалардан, сәйлән, комач, тасмадан гыйбарәт бизәнү әйберләре (күкрәкчәләр, бәйләвечләр, йөзекләр һ.б.) тулыландырган. Башларына җитен һәм киндер яулыклар, читләренә тасмалар тегелгән япмалар ябынганнар. Хатын-кызларның бәйрәмчә баш киемнәре – шлем сыман башлык (пухья), киселгән конус рәвешендәге башлык (хушпу).

Ирләр киеме – ак киндер күлмәк һәм ыштан (йем). Тышкы кием – киндер кафтан (шубёр), көзен – постаудан тегелгән кәзәки (сахман), кышын – сарык тиресеннән билле итеп тегелгән тун (керек). Ирләрнең җәйге баш киемнәре – кара яки ак киез эшләпәләр (ялкас), кышкылары – киң кырпулы һәм өсте гөмбәз сыман озынча бүрекләр (челек).

Чуашларның традицион аяк киемнәре – ыштырлы яки оеклы курыс чабаталар (чапата), күн итекләр.

**Милли аш-сулары.** Чуашларда нинди генә тәмле милли ризыклар юк. Чуашларның аш-суында үсемлек продуктларыннан әзерләнгән ризыклар өстенлек итә. Ит чагыштырмача сирәк, сезонлы (терлек чалганда) һәм бәйрәм ризыгы була. Туклану нигезен арыш икмәге (хура сакар) тәшкил итә. Чуашлар төрле ашлар (чумарлы, ярмалы), борщ, щи һ.б.; боткалар (карабодай, борай, бодай, ясмык), талкан, бәрәңге, солы һәм борчак оныннан кесәл (нимер), бөккән (кәбестә, җиләкләр белән), көлчә, дучмак пешерәләр.

Хуплу – түгәрәк, күп катламлы, төче камырга пешерелгән итле эчлекле бәлеш. Аның беренче катламы бәрәңге, икенчесе вак итеп туралган ит, өченче катламы шулай ук иттән яки майдан гыйбәрәт.

Пата − чувашларның милли боткалары. Аны төрле йола бәйрәмнәренә әзерлиләр. Уңыш мул булсын өчен чувашлар төрле махсус йолалар үткәргән. Анда төп сый булып пăтă саналган. Шулай ук бәйрәм өстәлләренә шăрттан, хуран кукли, тултармăш пешерәләр. Төп эчемлекләр – ачыган сөт (турах), әйрән (уйран), киндер орлыклары төнәтмәсе.

Халык саны буенча дөньяда 1миллион 500 мең чуаш яши дип фаразлана. Рәсәйдә 1 435 872 кеше дип исәпләнә. Чуашлар – Татарстан Республикасында сан буенча өченче милләт. Татарстан Республикасында 116 меңнән артык чуаш халкы яши. Чуашлар республикабызның Аксубай, Буа, Чүпрәле, Нурлат, Тәтеш, Чирмешән районнарында, Казан, Чаллы, Түбән Кама шәһәрләрендә гомер кичерәләр.

# I I бүлек

## Тәрбия чарасы буларак йола бәйрәмнәре

Һәр милләт үз җирлегендә барлыкка килгән һәм буыннан-буынга күчә торган гореф-гадәтләрен, кешеләрнең яшәү рәвешләрен, үз-үзләрен тоту кагыйдәләрен, карашларын, зәвыкларын сакларга омтылган. Тормыш–көнкүрештә билгеле бер йолалар үтәү, гореф-гадәтләрне тоту һәм бәйрәмнәр үткәрү барлык милләтләргә дә хас. Ул әлеге милләт мәдәниятенең мөһим бер өлеше булып исәпләнә. Гореф-гадәтләр борын-борыннан халык тарафыннан үтәлеп килә торган бәйрәмнәрне, йолаларны үз эченә ала. Билгеле бер йолаларның үтәлеп килүе җәмгыятьне дә тотрыклы итә, алардан башка халык тулы кыйммәтле тормыш белән яши алмый.

Халык бәйрәмнәре, йолалары – кешене тормыш тәртипләренә һәм таләпләренә күнектерергә ярдәм итә. Ул бәйрәмнәрне халыкның олысы-кечесе бергәләп уздыра. Яшь буын бәйрәмдә катнашу тәртибен кечкенәдән үк өйрәнеп үсә. Һәр кеше, табигый рәвештә, үз-үзен тоту гадәтләрен үзләштерә, милли тәрбия ала.

## Татар халкының милли йола бәйрәмнәре

Татар халкының гореф-гадәтләре- татарларның борынгы заманнардан бүгенге көнгә кадәр сакланып калган үзенчәлекләре. Алар бүгенге көндә дә үтәлә. Халыкның гореф-гадәтләре кешене тормыш тәртипләренә һәм тәлапләренә күнектерергә ярдәм итә. Бу бәйрәмнәрне халыкның олысы-кечесе бергәләп уздыра. Татар халкы борын-борыннан үзенең кунакчыллыгы белән дан тота, шуңа күрә хәзерге татарлар да аны безнең көннәргә кадәр сакланган традиция буларак аерып күрсәтә.

**«Сабантуй»**

Сабантуй – элек-электән халкыбызның һәрчак яратып, зур күтәренкелек белән үткәрелә торган олы бәйрәме ул. Сабан сүзе – сука дигән мәгънәне аңлата. Димәк, әлеге бәйрәм шуны аңлата: табигатьне уятучы яз басуларны эшкәртергә өнди. Ул язгы чәчүләр беткәч үткәрелгән. Моны, кагыйдә буларак, авыл картлары киңәшеп хәл кылганнар һәм бәйрәмне үткәрү көне турында базар көнне игълан иткәннәр. Шуның белән бергә, бер төбәктәге авыллар ярышларны төрле көнне үткәрергә омтылганнар. Бу башка авыл кешеләре дә күршеләренең бәйрәмендә катнаша алсын өчен эшләнгән. Сабантуен үткәрү өчен махсус урын билгеләнгән. Ул болын җир, аланлык булып, агачлар белән әйләндереп алынган тигез һәм уңайлы җирдә урнашкан. Бу урын мәйдан дип аталган. Һәр авыл өчен билгеле булган көнне – иртәнге якта яисә төштән соң хөрмәтле аксакаллар җыелган бүләкне мәйданга алып чыкканнар. Иң алдан ир уртасы кеше сөлге-яулыклар, ситсы бәйләнгән колга күтәреп барган. Мәйданда бүләкләрне аерым төр ярышлар өчен атап, билгеләп куйганнар. Сабантуенда нинди генә уеннар уйнамаганнар: йөгереш, баганага менү, авыш колгага менү, капчык киеп йөгерү, йомырка салынган

кашык кабып йөгерү, катыктан көмеш эзләү, чиләк-көянтә белән су күтәреп йөгерү һ.б. Сабантуйның төп ярышы булып көрәш тора. Көрәшне кечкенә малайлар башлап җибәргән, аннары яшүсмерләр, егетләр һәм ир-атлар көрәшкәннәр. Көрәштә җиңүчегә иң зур бүләк – сарык тәкәсе бирелгән.

**«Каз өмәсе» йола бәйрәме**

«Каз өмәсе» - көзен, кыш кергәндә казларны өмәләп эшкәртү чарасы. Каз өмәсе – ул матур итеп аралашу, күңел ачу, үзеңне күрсәтү дә булып торган. Каз мамыгыннан мендәр, түшәк, ястыклар ясыйлар. Каз итеннән аш-су өчен бик әйбәтләп файдаланалар.

Каз өмәсе һәр елны көз ахырында яисә кыш башында үткәрелә. Ул — бүтән өмәләрдән аермалы буларак, башыннан азагына кадәр кызлар өмәсе. Башка өмәләр кебек, каз өмәсен оештыру һәм уздыруның да үзенә генә хас тәртибе бар. Татар яшьләре каз өмәсен аеруча көтеп ала торган булганнар. Каз өмәсен бигрәк тә кызлар көтеп алган. Аннан читтә калмас өчен, алар бәбкәләре күп булган апаларга җәйдән үк сүз салып куйганнар. Бу гаиләгә охшарга, ярарга тырышканнар.Казлары күп кешеләр иртәгә өмә уздырыласы көнне кызларны чакырып чыгалар. Беренче чиратта туган-тумачаны, күрше кызларын дәшәләр. Гадәттә, өмәгә чакыру эше балаларга кушыла. Әйтелгән көнгә кызлар иртүк килә. Казларны эшкәртәләр, зур канатларын йолкып сыдыралар. Иң оста чистартылган казның бер генә шырпысы да (канат төпләре) калмый һәм бер җирдә дә тиресе ертылмый.

Казлар йолкынып, эчләре алынып, аяк-башлары чистартылып бетә. Өмәнең иң күңелле вакыты — чистартылган казларны, көянтә башларына элеп, кызларның су буена юарга баруы. Алар белән, сыдырылган канатларны алып, яшүсмер кызлар да бара. Алар канатларны су юлына бара торган сукмак буйлап тараталар. Монысы киләсе елда хуҗабикәнең казлары сукмакны тутырып йөрсен дигән теләк белән эшләнә. Кызларның кайберләре өй җыештырырга кала. Казларны елга суында юганнар. Гадәттә, гармуннар тагып, кызлар белән бергә егетләр дә чишмәгә төшкән. Казларны юып кайтышка, хуҗабикә каз маенда коймак, тәбикмәк пешереп, чәй әзерләп көтеп торган. Ашаганнан соң, кызларның бер өлеше, каз боткасы пешерү өчен, кәйледә ярма күзләргә (төеп чистартырга) китә. Караңгы төшәр алдыннан өмәдә катнашкан кызларның әниләре ашка чакырыла. Аларга каз шулпасында токмачлы аш, каз калҗасы белән бәрәңге, каз ите белән бәлеш пешерелә.

Каз өмәсенең иң кызыгы кич белән. Кызлар, матур күлмәкләрен киеп, өмә булган өйгә җыелалар. Җор телле, тап¬кыр сүзле кызлар ишек төбенә баса. Алар каз канаты «сата». Егетләр өйгә һөнәрләрен күрсәтеп, канат «сатып» алганнан соң гына кертелә.

Кунак җыю, кунак сыйлау татар халкында гомер-гомергә дәрәҗәле эш исәпләнгән. Туганнарың, күршеләрең, авылдашларың белән аралашып, ашка-суга йөрешеп яшәү тормышны тагын да ямьләндереп җибәргән. Өмәдә эшләнгән эшләр, уен-көлке хатын-кызга ел буена җитәрлек дәрт биргән. Ул көнне хатын-кызларның ни дәрәҗәдә уңган булулары ачыкланган.

**«Нәүрүз» бәйрәме**

Татар халкының борын-борыннан үткәрелеп килә торган бәйрәмнәренең берсе - Нәүрүз бәйрәме. Нәүрүз бәйрәменең исеменә килгәндә, фарсыча «ноу» - яңа, «руз» көн дигән мәгънәне белдерә. Ул төрки һәм көнчыгыш халыкларында Яңа елны каршылау бәйрәме буларак уздырыла килгән. Нәүрүз көнчыгыш календаре буенча мартның 21 нче көнендә, ягъни көн белән төннең тигезләшкән көнендә үткәрелгән һәм күп кенә җирләрдә, әйтик, фарсыларда, гарәпләрдә, Төркия, Азәрбайҗан Үзбәкстан, Төрекмәнстан, Казакъстан кебек илләрдә рәсмиләшкән дәүләткүләм бәйрәм сыйфатында хәзер дә уздырылып килә.

Бу бәйрәмдә яшьләр өйдән өйгә кереп, нәүрүз әйтеп (махсус шигъри әсәрләр сөйләп), бүләк җыеп йөргәннәр. Хуҗаларны яз белән котлаганнар. Бу, өйдән өйгә кереп, сөрән йөрүләрдә төрле кызыклы такмаклар, такмазалар, бәетләр сөйләп күңел ачканнар, хуҗаларның күңелләрен күргәннәр. Нәүрүзне алар чәчүгә әзерлек дип кабул иткәннәр. Мәсәлән, Карга боткасын гына алыйк. Ул шулай ук Нәүрүзнең бер күренеше. Аны икенче төрле "Дәрә" яки "Зәрә боткасы" дип йөртәләр.

Бәйрәм көнне иртән иртүк 8-10 кешелек балалар төркеме урамнарга чыкканнар һәм, йорттан-йортка кереп, "нәүрүз әйтеп", йомырка, ярма җыеп йөргәннәр. Йорт хуҗалары кичтән үк йомыркаларын төрле төскә буяп куйганнар. Соңыннан балалар, бергә җыелып, төрле уеннар уйнап, йомырка, ботка ашаганнар. Балалардан соң урамнарга атларга атланган егетләр чыкканнар. Алар бәйрәмгә чакырып, аваз салып йөргәннәр. Бу күренеш "сөрән салу" дип аталган. Яшьләр бергә җыелып, уеннар оештырганнар. Арадан иң чибәр, уңган кыз Нәүрүзбикә итеп сайланган. Җыелган халык "нәүрүз" җырлаган, бәетләр әйткәннәр. Нәүрүз көнне кеше күңелендәге гел изгелек кенә булырга тиеш. Ул игелек булып, аның үзенә үк кире кайтачак. Яңа елны ничек каршыласаң, елың шулай үтәр, дип уйлау күңелләрдә өмет уяткан. Кеше бу көнне бурычларыннан да котылырга тырышкан.

Бәйрәм вакытында уртак казанда пешерелгән аш белән барысын да сыйлау, бөтен кешенең дә тамашага уртак теләкләр белән килү гадәте үзе генә дә бик зур мәгънәгә ия бит! Нәүрүз тынычлык, дуслык, тигезлек бәйрәме ул.

# Рус халкының милли йола бәйрәмнәре

Русларның милли бәйрәмнәре христиан дине белән тыгыз бәйләнгән. Кайберсен христиан чиркәве үз йоласына әвереллдергән.

**«Май чабу» (Масленица бәйрәме)** Бу бәйрәмен атна буе билгеләп үтәләр. Бу атнада көн саен белен пешерелә. Белен- кояш символы. Кыш үтеп, яз житүне аңлата. Май чабу- кышны озату бәйрәме ул. Кешеләрдә төрле ышану һәм традицияләр коймак белән бәйләнгән. Коймак кешене бөтен тормышы буенча – туганнан алып һәм үлгәнчегә кадәр озата барган.

Май чабуны Сыр атнасы дип тә йөриләр. Христиан кануннары буенча бу Олы ураза алдыннан сөт, сыр һәм йомырка ашарга ярый торган атна. Май чабуның һәрбер көне билгеләнгән тәртиптә үткән, һәрберсенең исеме һәм максаты булган.

Беренче көн- «бәйрәм каршылау көне». Саламнан ясалган курчакны хатын-кыз киемнәренә киендергәннәр һәм яз килгәнне күрми калмасын өчен иң биек тау башына алып менгәннәр. Шуннан соң Май чабу башланды, дип саналган һәм һәр гаилә белен (коймак) пешерә башлаган. Чәршәмбе - «Тәмле тамаклар көне»ндә бер-берсенә кунакка йөрешкәннәр.

Кече атна - бәйрәмнең иң кызган көне. Бу көнне жигүле атларны жиз кыңгырау-шөлдерләр белән бизәп йөргәннәр, ат чабышлары үткәргәннәр, кул көрәштергәннәр, жырлаганнар, биегәннәр.

«Татар атнасы»- кияү әбисен каймак белән сыйлый торган көн.

Атна кич – утырмага килә торган көн (кич утыру)

Атна көн - «Кичерешү көне», Май чабуның соңгы көне. Бу көнне кич белән салам тутырып эшләнгән карачкы-курчакны яндырганнар, көлен уңыш мул булсын дип, басуга чәчкәннәр. Бу күңел ачуның соңгы минутлары була. Кич белән, бер-берсеннән кичерешү сорыйлар. Жиргә кадәр баш иеп бер-берсеннән иске үпкәләрне кичерү сораганнар. Гаиләдә кичерүне икенче төрле сорыйлар. Кичке аштан соң барысы да Иман әйтә, а аннан соң гаиләдә иң кечесе һәр кешегә чиратлап баш иеп чыга һәм кичерү алып, читкә китә. Аннан соң яшь буенча барысы да шулай эшләп чыга, ә кечерәкләргә инде баш имиләр һәм аннан кичерү сорамыйлар. Соңгы булып хужа хатын иренә генә баш ия һәм иреннән генә кичерү сорый. Йорт хужасы, ир кеше, беркемгә дә баш ими. Май чабу узганнан соң, мунча кергәннәр.

Чынлап та бу көннәрдә халык жыелышып, гармуннар белән жырлашып, шаярашып атларда йөргәннәр. Күп кенә Май чабу йолалары туйларны тизләтүгә, ялгыз яшьләргә үз парларын табуда ярдәм итүгә юнәлдерелгән була.

**«Иван Купала» (борынгы славян бәйрәме)** Бу бәйрәмне 6 нчы июльдән 7 нче июльгә каршы төндә билгеләп үтәләр. Кызлар тәкыяләр үрә һәм аларны суга агызып җибәрә. Иван Купала вакытында урманда абага чәчәге эзлиләр. Борынгы риваятьләр буенча, аңа ия булучыга дөньяның барлык серләре ачыла.

Күмәк күңел ачулар вакытында яшьләр учак аша сикерә, әйлән-бәйлән уйный, ә кичен елга буенда факелларны сүндерә һәм иртәнгщ кадәр су коена.

**«Каравон» (борынгы рус халык бәйрәме)** Бу бәйрәм 22 майда изге Николай Чудотворец истәлегенә билгеләп үтелә. Каравон вакытында түгәрәк әйләнү уены, үлән курчаклар ясау кабул ителгән. Бәйрәмдә халык җыр ансамбльләрре чыгыш ясый, һөнәрчеләләр үз осталыгын күрсәтә. Түгәрәк әйләнгәндә махсус «каравон» («үрдәк») адымы белән йөриләр. Шул рәвеәле түгәрәк, бер кечерәеп, бер зураеп, әкрен генә «кояш уңаена» әйләнә.

## Чуаш халкының милли йола бәйрәмнәре

**«Уяв» бәйрәме.** Бу бәйрәм язгы кыр эшләре тәмамланганнан соң башлана, җәйге кызу эш вакыты – печән өсте, уракка төшү алдыннан тәгәлләнә; еш кына Питрау көненә туры китерелә. Уяв 3, 5, 7 (так сан булуы мәҗбүри) атна дәвам итә.
Гадәттә көндезге һәм төнге уявлар уздырыла.
Төнге уяв вакытында яшьләр күбрәк җырлап-биеп күңел ачалар. Уявны үткәрү вакыты һәм төрле тыюлы көннәр авылның өлкән кешеләре тарафыннан билгеләнә.
Көндезге уяв өчен 2 (җомга һәм якшәмбе) яки 3 (чәршәмбе, җомга, якшәмбе) көн билгеләнә.
Уяв мул уңыш сорап гыйбадәт кылудан башлана, корбан чалу белән дәвам итә, чама белән бер атнадан яңгыр сорап гыйбадәт кылу белән тәгәлләнә.
Бу вакыт аралыгында җир эшләре башкару, караңгы төсләрдәге һәм чуар тукымадан тегелгән киемнәр кию, кер юу, биналарны җыештыру һәм юу тыела. Шулай ук ут кабызу, самавар кую, кайнар азык ашау рөхсәт ителми. Алдан әзерләгән ризыкны җылытмыйча ашыйлар.

Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы булышлыгында даими рәвештә чуашлар тупланып яшәгән Аксубай, Чүпрәле, Нурлат һ.б. районнарда **«Уяв»** бәйрәме үткәрелә.

## Башкорт халкының милли йола бәйрәмнәре

**«Жыен»** (башкортча –«йыйын»)- башкортларның иң борынгы, башка халыкларда булмаган бәйрәме. Борынгы заманнарда ул сәяси мәсьәләләрне хәл итү, мөһим вакыйгаларга нәтиҗә ясау, уңган-булганнарны ачыклау урыны булган.

Бәйрәмнең төп үзенчәлекләре: ул җәйге вакытта, язгы чәчү эшләре бетеп, печәнгә һәм уракка төшкәнче үткән. Жыенны традициядән килгән билгеле бер вакытта берничә авыл бергә үткәргән. Икенче атнада башка «даирә» авыллары бәйрәм иткәннәр, һәм бәйрәмнең чираты да традицион булган. Жыенда күбесенчә ир-атлар гына катнашкан. Хәзерге Жыеннар күбрәк күңел ачу чарасы рәвешендә үтә. Төрле бәйгеләр җыр-бию белән үрелеп бара. Бәйрәмдә башкорт халкының милли ризыклары белән дә сыйланырга була.

## Мари халкының милли йола бәйрәмнәре

**«Семык» бәйрәме.** Бу бәйрәм марыйларның язгы чәчү эшләрен тәмамлау һәм җәй җиткәнен белдерүче милли бәйрәмнәре. Бу бәйрәмдә хуҗалык эшләрендә, көнкүреш тормышта уңышлар юлдаш булсын дип теләнелә, мәрхүм булганнар искә алына. Борынгы заманнарда аны Пасхадан (Күгече) соң 7 атна үткәч оештыра торган булганнар. Ул Троица атнасында башлана һәм атна ахырында тәмамлана. Мари халкы күмәк, дус булулары белән аерылып тора. Бәйрәмне дә берничә гаилә яки авыл берләшеп уздырган.

Семык атна буе дәвам иткән. Дүшәмбе һәм сишәмбе бәйрәмгә әзерлек буларак юу, җыештыру эшләре белән бәйле булган. Марилар фикеренчә, бу көнне үлгән кешеләрнең җаннары туганнары белән күрешер өчен өйгә кайта. Чәршәмбе мунча ягып керү һәм табын әзерләү таләп ителгән. Өстәлгә коймак, эремчек, йомырка, май һәм төрле эчемлекләр куелган. Өй хуҗасы шәмнәр яндырып, мәрхүмнәрнең исемнәрен атап чыккан, бу ел өчен фатиха соралган һәм урамга чыгып аларны «озатканнар». Мари халкының ышанулары буенча, Семык бәйрәменең чәршәмбе кичендә һәм төнендә урам буйлап «кара көч» йөри икән. Алар төрле хайван һәм кош сурәтләренә кереп бозым тарата дип ышанганнар. Шуңа күрә ишек, тәрәзәләрне ябып, өйдә учак якканнар. Төнлә яшьләр кырга чыгып төрле уеннар уйнаган, чәчәкләр җыйган. Ботаклардан такыя (тул орва) үреп, аңа ут кабызып таудан тәгәрәткәннәр. Пәнҗешәмбе көн марилар яңадан мунча ягып, табын әзерләгән. Зиратка барып мәрхүмнәрне «сыйлап», сәламәтлек һәм уңышлар теләнгән. Җомга – бәйрәмнең иң

күңелле көне. Ул көнне еш кына туйлар үткәрелгән, халык күмәкләшеп рәхәтләнеп ял иткән.

## Мордва халкының милли йола бәйрәмнәре

Июнь ахырында Троицадан соң беренче якшәмбе көнне Лениногорск районының Мордовская Кармалка авылында «Балтай» дигән бәйрәм уздырыла. Кармалкада эрзяләр яши. Алар Алладан бәхет һәм сәламәтлек сорап ел буе гыйбадәт кылалар. Июнь ахырында эрзялар Шкай Алладан мул уңыш сорап «Веле озномс» дигән җәмәгать бәйрәме дә оештыра. Эрзялар кешеләрне урман җәнлекләреннән килеп чыккан дип уйлый. Шуңа аюдан сәламәтлек сорап махсус гыйбадәтләр уздыралар.

Мордовская Кармалка авылында бер риваять саклана. Имеш 1902 елда авыл янында Балтай исемле карт торган. Бер көн ул авыл халкының кәефен күтәрү өчен аю тунын кигән рәвеш чыгарып, өрәңге ботакларыннан кием ясап кигән. Нәкъ шул вакыттан «Балтай» дигән бәйрәм оештырыла башлый. Аны башкача «Овто чи» («Аю көне») дип тә атыйлар.

**«Балтай» бәйрәме.** Бу бәйрәм ел саен ата-бабалардан килгән бер тәртиптә бара. Йолаларның дөрес үтәлешен карап йөрүче дә бар. Ә йолалар бик кызыклы. Иң элек бөтен кешеләр «Балтай аланында» җыела. Аксакал махсус мордва уены ярдәмендә уенчылардан өч «аю» сайлый. Күзләре бәйләнгән килеш уенчылар кикерон (кабык шарлар) җыярга тиеш. Кем күбрәк җыя – шул «аю» була.

«Балтай»да өч егеткә өрәңге агачы ботакларын «аю туны» итеп кидереп, авыл буйлап «аю юлы» белән баралар. Бик күңелле итеп «Кий чиресэ репст видезь» милли җырын җырлап-биеп, «аюларны» тәм-томнар белән сыйлап бөтен авылны урыйлар. Әйбәтләп сыйласаң – уңыш мул, тормыш имин була дип ышанганнар. Юлны кое янында тәмамлыйлар, «аю»ларны чишендерәләр һәм киеменнән берәр ботак алалар. Шуны бер-берсенә сарып, «Шумбрачи!» диеп бәхет-шатлык телиләр. Балалар кое янына җыелышып бер-берсен су белән коендыралар, шулай итеп алар табигатьтән яңгыр һәм «аю көче» сорыйлар.
«Балтай» кунакларын «суронь пачалксеть» дигән коймаклар белән сыйлыйлар. Ул бодай оныннан пешерелә. Шулай ук мордвалар «офтонь лапат» («аю тәпие») дигән ит кәтлитләре, «прякат» дип аталучы кәбестә, яшел суган, бәрәңге, яисә боткалы тәмле пироглар пешерәләр.
Бәйрәмнең төп герое - аю. Риваятьләр буенча, бу якларда кешеләргә урман нигъмәтләре өчен урман хуҗасы аю белән көч сынашырга туры килгән. Кеше ерткыч җанварны җиңгән, шул уңайдан бәйрәм итә башлаганнар. Шуңа күрә бәйрәм көнне авылдагы бер ир-егетне аю итеп киендерәләр - өрәңге агачының яшел яфраклы ботакларына төрәләр дә,

аны ияртеп, авыл буенча һәр йортка кереп, хуҗаларга имин тормыш теләп йөриләр. Бәйрәм аюны чишендерү йоласы белән тәмамлана, аю киемендәге агач ботакларны алып, һәркем үзен һәм башкаларны бәхет, уңышлар тели-тели чабындыра.

## Удмурт халкының милли йола бәйрәмнәре

**«Гырон быдтон» бәйрәме**. Бу бәйрәм җәйнең иң матур вакытында болында уздырыла. Удмуртлар 1 июньдә Вось дигән илаһлары «Куалы» дип аталган гыйбадәтханәләреннән болын-кырларга чыгып оча һәм кире Питраудa (12 июньдә) гына кайта дип ышаналар. Шуңа күрә бу вакытта алар гыйбадәтханәләрдә түгел, ә табигать кочагында дога кылалар.

Иртән гаилә белән басуга чыгалар, агач көрәкләр белән кечкенә чокыр казып, анда үзләре белән алып килгән ризыкны (пәрәпәч, йомырка һ.б.) салып күмәләр. Авыл халкы бергә җыела, зур казаннарда аш һәм ботка пешерелә, Алладан аяз һава торышы, сәламәтлек, җылы яңгыр һәм яхшы уңыш сорала. Бәйрәм кунакларын ритуаль ботка, башка милли тәм-томнар белән сыйлыйлар. Мәйданда традицион милли ярышлар, спорт уеннары уза.

Республикабызда удмуртларның «Гырон быдтон» бәйрәмен билгеләп үтү 1998 елда кире кайтарылды. Бәйрәмдә төрле йолалар, республиканың төрле районнарыннан, Удмурт Республикасыннан килгән төрле фольклор ансамбльләре чыгыш ясый.

**«Выль Джук» бәйрәме.** Бу бәйрәм удмурт халкының беренче уңыш өлгерүгә багышланган милли бәйрәме. Удмурт теленнән тәрҗемә иткәндә Выль Джук – «беренче уңыштан пешерелгән арпа боткасы» дигәнне аңлата. Йола буенча бу көнне бөтен ризыкны яңа уңыштан әзерләргә кирәк. Кул көче белән киптерегән бодай бөртекләрен тарттырып, он ясаганнар, шуннан икмәк пешергәннәр. Солыдан кисель болгатканнар. Кырлардан алып кайткан бодай һәм арпа башакларын, яшелчә яфракларын ашка тыгып изгеләндергәннәр. Шуннан соң мәҗүсиләрнең Инмар Алласына дога кылганнар, киләсе елда да мул уңыш булуын сораганнар. Һәр йортта тук башаклар һәм яшелчә яфраклары эленеп торырга тиеш булган. Йоланың төп өлеше булып, Инмар Алласына корбан китерү торган. Моның өчен ит, май салып пешерелгән ботканы махсус агач янына алып килгәннәр һәм әлеге агачка тасмалар бәйләгәннәр. Шуннан соң җыр-биюләр, күңел ачу башланган.

Башка елларда бу йола удмуртлар яшәгән авылларда гына искә алынса, хәзер район күләмендә, Кукмараның Комсомол мәйданында бәйрәм итело башлады.

# I I I бүлек

## Дуслык һәм бердәмлек хисләре үстерүдә халык уеннары

**Халык уеннары** —халыкның тарихи яктан нығыган күңел ачуы, уен-көлке, тамаша кылу чаралары һәм спорт, җыр бәйгеләре. Һәр халыкның уеннары мәдәният традицияларында формалашкан һәм үз халкының тарихы, хезмәте, көнкүреше һәм йолалары белән бәйле рәвештә үскән. Уендарда балаларның кайберләре катнашучыларның узышыуына, ярышыуына сөенсә, икенчеләре осталыкларын күрсәтүгә шатлана, өченчеләре дөнъяны танып белергә өйрәнә.

Көндәлек тормышта сабыйларның дөнъяны танып белүенә, физик һәм рухи яктан үсешенә, дуслык, бердәмлек хисләре тәрбияләргә, сәләтләрен ачуга, үзара мөнәсәбәтләр корырга өйрәтүдә уеннар ярдәмгә килгән. Уеннар- балачакның алтын бизәге бит ул!

«**Тирмә»** (башкорт халык уены)

Уенда дүрт баладан торган дүрт төркем бала катнаша. Алар залның дүрт почмагында түгәрәк ясап басалар. Һәр төркемнең уртасында милли бизәкле зур матур яулык белән капланган урындык урташтырылган. Төркемдәр дүрт мөйөшкә урынлаша. Уртала ултырғыста милли биҙәкле яулык ята. Балалар төркөмнәрендә барысы бергә кулга кул тотынышып, җырлап әйләнәләр.

Без, күңелле шат балалар,
Уйныйбыз да биибез.
Зур түгәрәккә җыелып,
Матур тирмә ясыйбыз.

Көй туктап җырлап бетергәч, үз урындыклары янына барып, яулыкларын «тирмә» ясап күтәрәләр. Кайсы төркөм беренче төзи, шул җиңә.





(«Тирмә» уенынан күренеш)

**«Әбәк- күбәк»** (башкорт халык уены)

Балалар арасыннан «көтүче» сайлана. Калганнар бер-бер артлы тезелеп басалар. Көтүче үз алдындагы баланың кулына кагыла (акрын гына суга) һәм болай ди:

Әбәк- күбәк, алтын савыт,

Куып тотсаң – алтын кашык,

Әгәр тота алмасаң,

Эзеңә җитмеш көрәк көл.

Бу сүзләрнеә бетергәннән соң, ул йөгереп китә. Кулына кагылган бала аның артыннан куа. Әгәр көтүче, йөгереп барып, колонна артындагы бала артына басарга өлгерсә, куучы җиңелгән санала, һәм ул көтүче була. Әгәр өлгермәсә, уен нәкъ шул тәртиптә кабатлана. Уен шулай дәвам итә.

**«Ак тирәк- күк тирәк»** (башкорт халык уены)

Балалар икегә бүленеп, бер-берсенән 20—30 метр ераклыкта тезелеп басалар. Уйнаучылар бер-берсе белән кулга-кул тотынышалар. Бер яктагылар икенче яктагыларга кычкырып такмаклыйлар:

Кабыр-кабыр кабырчак,
Ат башында кимерчәк.
Ак тирәк- күк тирәк
Бездән сезгә кем кәрәк?
*Каршы яктагылар җавап бирәләр:*
Кап- кап кабырчык,
Кабырчыгым кимерчәк,
Ук аттым, батмады,
Һәмгелсәгем катманы,
Ак та тирәк- күк тә тирәк
Энә белән җеп тә кирәк,
Ҡашығаяҡ йыуылмаған,
Аҡ тирәк күк тирәк
Ал да кирәк, гөл дә кирәк,
Безгә иң матур җырчыбыз
Алма атлы кыз кирәк.

Исеме чыкҡан уенчы каршы як сафтан йөгереп барып өзеп чыгарга тырыша. Өзә алса, бер уенчыны ияртеп үз ягына алып чыга. Өзә алмаса, шул яҡта кала. Уен шул тәртиптә, бер яҡта уенчылар беткәнче дәвам итә.

## **«Күрсәт әле, үскәнем» уены** (татар халык уены)

Балалар түгәрәк ясап басалар һәм иптәшләреннән берсен уртага чыгаралар да, күмәк җырлап әйләнеп, уртадагы балага төрле эшләр кушалар. Уртадагы бала кушылган эшне башкара. Кырыйдагылар да: “Менә шулай, менә шулай”, дип, ул эшләгән эшне кабатлыйлар. Эш кушу өчен түбәндәге такмаклар файдаланыла:

1. Күрсәт әле, үскәнем,

Ничек җилләр исәләр?

Менә шулай, менә шулай,

Шулай җилләр исәләр.

2. Күрсәт әле, үскәнем,

Ничек кошлар очалар?

-Менә шулай, менә шулай,

Шулай кошлар очалар.

3. Күрсәт әле, үскәнем,

Ничек куян сикерә?

Менә шулай, менә шулай,

Шулай куян сикерә.

4. Күрсәт әле, үскәнем,

Ничек йөри аюлар?

-Менә шулай, менә шулай,

Шулай йөри аюлар.

## **«Чума үрдәк, чума каз» уены** (татар халык уены)

Балалар парлап бер-берсенә карап (тезелешеп басалар. Бер бала так кала, ул балаларга карап баса. Балалар бала исемен әйтеп җырлыйлар. Җыр бетүгә, так калган бала саф арасыннан үтә, үзенә пар таба, артка барып басалар. Ялгыз калган бала алга чыгып баса, уен дәвам итә.

Чума үрдәк, чума каз,

Чума үрдәк, чума каз,

Тирән күлне ярата шул, ярата.

Тирән күлне ярата шул, ярата.

Булат үзенә иптәш сайлый

Булат үзенә иптәш сайлый,

Белмим кемне ярата шул, ярата.

Ул ...... ярата шул, ярата.

«**Кәрия-Зәкәрия»** (татар халык уены)

Балалар түгәрәк ясап басалар һәм иптәшләреннән берсен уртага чыгаралар да аның турында җырлыйлар. Кушымтаны җырлаганда уртада торучы бала бии, башкалар кул чабалар.

Бу бик яхшы укучы,

Бу бик яхшы укучы.

Аның укуы яхшы,

Аннан үрнәк алыгыз.

Кәрия — Зәкәрия коммая,

Кария — Зәкәрия коммая,

Кәри комма, Зәкәрия,

Зәкәрия коммая.

Бу бик яхшы җырлаучы,

Бу бик яхшы җырлаучы.

Аның җырлавы яхшы,

Аннан үрнәк алыгыз.

**«Су анасы»** (удмурт халык уены)

Җмргә зур түгәрәк сызыла. Бу – «күл» («елга»). Санамыш ярдәмендә «су анасы» сайлана. Ул күл эчендә утыра. Уйнаучылар күл тирәли йөгереп йөриләр. Күл янына якын килгән балаларны су анасы тота (кулы белән кагыла). Тотылган бала күл эченә керә. Уен берниче тапкыр кабатлана. Уенга күрсәтмәләр: • Су анасы сызыктан чыгарга тиеш түгел.

• Тотылган балалар су анасына калган балаларны тотарга булышалар.

**«Тили-рам, бездән сезгә кем кирәк?»** (чуваш халык уены)

Уенда ике команда катнаша. Ике команда бер-берсенә кара-каршы басып тора. Беренче команда бергәләп әйтә: «Тили-рам, тили-рам?» (Сезгә кем, сезгә кем?) Ә икенче команда кулга-кул тотынып, беренче командадан бер уенчының исемен әйтә. Исем әйтелгән бала икенче якка йөгереп чыга. Аннан рольләрне алыштыралар. Ахырдан командалар, бер-берсе белән канат ярдәмендә тартышалар.

**«Аю янында, урманда»** (рус халык уены)

Бу уенны иң нәни балалар белән дә уйнарга мљөмкин. Катнашучылар арасыннан бер бала «аю» итеп билгеләнә. Мәйданчыкта ике түгәрәк сызыла, беренчесе – «аю өне», икенчесе – зуррагы – балалар өчен «өй».

Уен башлану белән, балалар өйләреннән чыгалар һәм җырлыйлар:

Аю янында урманда

Киләм, гөмбәләр җыям,

Аю үзе йокламый,

Безне тотарга тели.

Балалар шул сүзләрне әйтү белән, аю өненнән йөгереп чыга һәм балаларны куа башлый. Үз өйләренә кереп өлгергән балаларга аю тия алмый, ә тотылган баланы үз өненә алып китә.

**«Тилгән»** (рус халык уены)

Уйнаучылар арасыннан «тилгән», «тавык» сайлана, калган балалар «чебиләр» булалар. Чебиләр бер-бер артлы тезелеп басалар, тавык аларның алдында тора. Тилгән бер читтә утыра, «чокыр казый». Тавык чебиләре белән аның тирәсендә әйләнеп йөри. «Тавык» белән «тилгән» сөйләшәләр:

Тилгән, тилгән, син нишлисең?

Чокыр казыйм.

Сиңа чокыр нәрсәгә?

Акча эзлим.

Сиңа акча нәрсәгә?

Энә сатып алырга.

Сиңа энә нәрсәгә?

Капчык тегәргә.

Сиңа капчык нәрсәгә?

Синең балаларыңны салырга.

Шуннан сң тилгән иң арттагы чебине тотып ала да, читкәрәк илтеп, «капчыкка» сала. Капчыктагы балалар шул урыннан китә алмый, уенны күзәтеп торалар. Тавык чебиләрнең алдына барып баса, балаларын саклый. Әмма тилгән башка чебиләрне дә тотып бетерә. Барлык чебиләр тилгән кулына эләгеп беткәннән соң, уен тәмамлана.

**«Кулъяулык белән уен»** (удмурт халык уены)

Балалар парлашып түгәрәккә басалар. Ике алып баручы билгеләнә, берсенә кулъяулык бирелә. Сигнал булгач, кулъяулыклы алып баручы йөгереп китә, ә икенчесе аны куа. Алар түгәрәкнең тышында куышалар. Кулъяулыклы алып баручы парлашып басып торучы балаларның берәрсенә кулъяулыкны тапшыра, үзе аның урынына баса. Шулай итеп кулъяулыклы алып баручы алмашына. Парсыз калган алып баручы кулъяулыклы баланы куып китә.

**«Түгәрәктә»** (мордва халык уены)

Җирдә зур түгәрәк сызыла. Уйнаучылар ике командага бүленәләр һәм команданың берсе – түгәрәк эченә, икенче командада уйнаучылар түгәрәкнең тышына урнашалар.

Түгәрәкнең тышында басып торучы балалар тигез итеп бүленәләр һәм, түгәрәк эчендәге балаларга тидерергә тырышып, туп ыргыталар. Әгәр дә түгәрәк эчендә басып торучы балаларның берәрсе тупны тотып ала икән, ул аны тышта басып торучыларга таба ыргыта. Әгәр дә ул тупны кемгә дә булса тидерә алса, аңа бер очко бирелә; тидерә алмаган очракта, ул уеннан чыга. Түгәрәк тышында басып торучыларның барысына да туп тидерелгәннән соң, уенчылар урыннары белән алышыналар.

**«Биләш»** (мари халык уены)

Бер-берсеннән 3–4 метр ераклыкта 2 сызык сызыла яки 2 бау сузыла. Уйнаучылар, ике командага бүленеп сызык артына тезеләләр. Беренче командадан берәү «биләш» дип кычкырып, каршы командага таба йөгерә. Каршы командада һәр уенчы ул килүгә уң кулын сузып тора. Йөгереп килүче үз теләгән баланы кулыннан тотып ике сызык арасына алып чыга һәм алар тартыша башлыйлар (кулны ычкындырырга яки ике кул белән тотынырга ярамый). Кем каршы якның сызыгын үтеп чыга, шул җиңелүче-каршы командага күчә һәм җиңүченең артына баса.



# I V бүлек

## Балаларны уйланырга, фикер йөртергә өйрәтү чарасы буларак- дидактик уеннар

## Дидактик уен «Курчакны милли киемгә киендер!»

***Бурычлар:*** балаларда төрле милләт халыклары турында күзаллау формалаштыру (татар, урыс, марый, мордва, бурят, дагестан һ.б.), бу халыклар белән кызыксыну уяту, милли үзаң формалаштыру, хәтер һәм фикерләү сәләтен, милли төсләр колориты һәм эстетик зәвык үстерү.

***Материал:*** катыргыдан ясалган малай һәм кыз курчаклары, шул курчаклар размерына кәгазьдән эшләнгән төрле милләт халыкларының милли киемнәре.



***Уен барышы:*** уенда берничә бала катнаша ала. Үзе теләгән милләтнең милли киемнәрен курчакка киертә һәм һәр киемнең аталышын әйтә.(удмурт малае-киез эшләпә, кыек якалы күлмәк, билбау, чалбар, аяк киеме яки удмурт кызы- яулык, бәйләвеч, күкрәкчә, күлмәк, алъяпкыч, оек)

## Дидактик уен-лото Милли ризыкларны таны һәм ата!»

***Бурычлар:*** Төрле халыкларның милли ашлары турында булган белемнәрен ныгыту, хәтер һәм логик фикерләү сәләтен үстерү, бу халык белән кызыксыну уяту, хезмәт кешесенә хөрмәт тәрбияләү.

***Материал:*** Төрле халыкларның милли ашлары сүрәтләнгән зур һәм вак рәсемнәр.



***Уен барышы:*** уенда берничә бала катнаша ала. Үзе теләгән милләтнең милли ашы сүрәтләнгән зур рәсемне ала һәм һәр рәсем өстенә вак рәсемнәрне табып бу милли ашның ничек аталуын әйтә. (башкорт милли ризыклары: бавырсак)

## Дидактик уен «Милли домино»

***Бурычлар:*** Балаларны татар халык орнаментлары белән таныштыру, игътибарлылык, күзәтүчәнлек, логик фикерләүне камилләштерү.

***Материал:*** Милли бизәкләр төшерелгән доминолар.



***Уен барышы:*** Уенда 4-5 бала катнаша. Балаларга карточкалар милли бизәкле доминолар бүлеп бирелә. Иң беренче алып баручы бер доминоны өстәлгә куя. Балалар анда нинди бизәк сүрәтләнгәнен әйтәләр. Һәр бала үзенең карточкасыннан шундый сүрәтне эзли, әгәр туры килсә өстәлдәге домино янәшәсенә куя.

Кем беренче үзендә булган орнаментлы доминоларны куеп бетерә- шул җиңүче була.

## Дидактик уен «Бу нәрсә?  Ни өчен кирәк?»

***Бурычлар:*** Рус халыкының йорт кирәк-яраклары турында булган белемнәрен ныгыту, хәтер һәм логик фикерләү сәләтен үстерү, бу халык белән кызыксыну уяту, хезмәт кешесенә хөрмәт тәрбияләү.

***Материал:*** Рус халыкының йорт кирәк-яраклары  сүрәтләнгән рәсемнәр.

***Уен барышы:*** уенда берничә бала катнаша ала. Рус халыкының йорт кирәк-яраклары сүрәтләнгән рәсемнәрне балалар чиратлашып алалар һәм нәрсә икәнен әйтәләр, нигә кирәк булуын ачыклыйлар.(мич, табагач, самовар...)



## Дидактик уен «Парын тап!»

***Бурычлар:*** Карточкадагы матрёшкаларның төсләре һәм күлмәкләрендәге орнаментлары буенча чагыштырып карап, аларның бер-берсенә охшаган якларын табарга; аларны сайлап алырга булышу; иҗади күзаллауларын формалаштыру.

***Материал:*** 2  өлешкә киселгән матрёшкалар ясалган карточкалар.

***Уен барышы:*** уенда бер бала яки төркем катнаша ала. Тәрбияче 2  өлешкә киселгән матрёшкаларны күрсәтә, балаларга игътибар белән карарга вакыт бирә. Балалар карточкадагы матрёшкаларның төсләре һәм күлмәкләрендәге орнаментлары буенча чагыштырып карап, аларның өлешләрен табалар.



# V бүлек

## Әхлак тәрбиясе бирүнең бер юнәлеше- халык әкиятләре

**Өч кыз** (Татар халык әкияте)

Борын-борын заманда булган икән, ди, бер Хатын. Аның булган, ди, өч кызы. Бу Хатын, кызларымның өсте бөтен, тамаклары тук булсын, дип, көне-төне эшләгән, ди. Менә кызлар үсеп буйга да җиткәннәр. Алар берсеннәнберсе матур, ди, бер битләре ай, бер битләре кояш, буй сыннары карлыгачтай сылу, ди. Өч кыз, бер-бер артлы кияүгә чыгып, берсе артыннан берсе китеп тә барганнар. Менә бер ел үткән, ике ел, өч ел үткән. Шулай матур гына яшәгәндә, әниләре авырып киткән. Күрше урманда Тиен дусты бар икән, шуны дәшеп әйткән:

— Тиен дустым, барсана, кызларыма әйтсәнә, хәлемне белергә килсеннәрче, — дигән.

Тиен шунда ук чыгып чапкан. Тиен барып тәрәзә какканда, Олы кыз җиз ләгәннәр чистартып торадыр иде, ди.

— Һай, — дип әйткән, ди, Олы кыз, — бик барыр идем дә бит, аңарчы менә шушы ләгәннәрне чистартып бетерәсем бар иде шул, — дигән, ди. Тиен моңа бик ачуланган да әйткән:

— Алайса, син шушы ләгәннәреңнән мәңгегә аерылма! — дигән.

Тиеннең шулай дип әйтүе булган, ике ләгән кызны ике яктан китереп тә кысканнар. Олы кыз егылган да шунда ук гөберле бакага әверелгән. Тиен Уртанчы кызга чапкан. Уртанчы кыз, бу кайгылы хәбәрне ишеткәндә, киндер суга икән. Тиенгә әйткән:

— Һай, — дигән, ди, — әнием янына хәзер үк чыгып йөгерер идем дә бит, менә ярминкәгә киндер сугып өлгертәсем бар иде шул, — дигән.

Тиен бик ачуланган да әйткән:

— Алайса, син гомереңбуе киндер сугып кына тор! — дигән.

Уртанчы кыз шунда ук үрмәкүчкә әверелгән. Тиен тәрәзәсен какканда, Кече кызның камыр баскан чагы икән. Ул бер сүз дә әйтмәгән, камырлы кулларын да сөртеп тормаган, чыккан да әнисе янына йөгергән. Тиен Кече кызга әйткән:

— И сөекле бала, гомер буе игелек күр, кешеләрне бәхетле ит, аларга куаныч та, юаныч та бул. Кешеләр дә сине сөярләр, синең яхшылыгыңны мәңге онытмаслар, — дигән.

Кече кыз, чыннан да, бик рәхәт гомер кичергән, халык аны бик яраткан, ди.

**Алтын бөртекләр** (Татар халык әкияте)

Борын-борын заманда бер ир белән хатын яшәгәннәр. Аларның биш уллары булган. Бердәнбер көнне боларның әтиләре, Туган илне яклап, яуга киткән. Ул кире әйләнеп кайтмаган, сугыш кырында үлеп калган. Ялгыз ана биш малайны үзе генә тәрбияләп үстергән.

— Улларым, - дигән ана, егетләрне үз янына чакырып алган да, мин сезне үстердем, хәзер үз көнегезне үзегез күрегез, -дигән.

— Без, үз көнебезне үзебез күрер идек, акчабыз юк бит. Син, әни, безгә берәр генә бөртек булса да алтын бир,- дигәннәр егетләр .

— Алтын бирәм,- дигән ана,- бер бөртек түгел, мең бөртек. Тик ул алтыннарны әтиегез җыеп куйган иде. Аны үзегез эзләп табыгыз!

— Табабыз, табабыз! — дигәннәр егетләр.

— Ә-әнә, — дигән ана,- Ташлытау белән Карлытауны күрәсезме? Шул ике тау арасындагы киң басуны күрәсезме? Шул басуга әтиегез алтын бөртекләре күмгән иде. Эзләп табыгыз шуны. Басуның җирен казыгыз. Җиң сызганып, тир сыпырып эшләгез.

Биш егет биш сабан белән күз күреме кадәр җирне сөреп чыкканнар. Аннары кәсләрне ваклап, тырма белән тырмалаганнар. Ә алтын бөртекләрен тапмаганнар. Шуннан егетләр, бик күңелсезләнеп, әниләре янына кайтканнар.

— Бер генә бөртек тә алтын тапмадык, әни! — дигәннәр.

— Борчылмагыз, улларым! — дигән ана.- Табарсыз алтыннарны! Әнә бурадагы бодайны илтеп чәчегез шул җиргә, көз көне бодайны ургач, камылын йолкырсыз, бодай тамырына алтын бөртекләре эләгеп чыгар.

Егетләр әниләре әйткәнчә эшләгәннәр. Бодай мул уңган, аны урганнар, сукканнар.

— Китерегез миңа үзегез иккән игенне!- дигән ана.

Егетләр әниләре алдына капчык-капчык игенне китереп өйгәннәр. Ана кызгылт-сары бөртекләрне учына алып караган да улларына әйткән:

— Әтиегезнең җиргә күмгән алтын бөртекләре менә шулар инде, улларым. Сез менә аларны эзләп таптыгыз. Инде хәзер үзегез көн итә алырсыз!

Егетләр бер-берсенә караганнар да бәхетле елмайганнар.

**Казлар-аккошлар** (Рус халык әкияте)

Бер Карт белән бер Карчык торганнар, ди. Аларның бер Кызы белән бер бәләкәй Малайлары булган, ди. Бервакыт Карт белән Карчык базарга барырга җыенганнар.

— Кызым, Кызым! Без базарга барабыз, син өйдә утыр, кечкенә энеңне кара, ул беркая да китеп йөрмәсен. Без сиңа яңа күлмәк алып кайтырбыз, — дигәннәр.

Тиздән Кызның әтисе белән әнисе чыгып киткән, ә кыз, әнисенең әйткәннәрен онытып, энесен тәрәзә каршындагы чирәмгә утырткан да, үзе урамга чыгып киткән. Уен белән мавыгып, ул энесен бөтенләй исеннән чыгарган. Шулчак, көтмәгәндә, әллә кайдан казлар-аккошлар килеп чыкканнар, малайны канатларына утыртканнар да алып киткәннәр.

Кыз өйгә кайтса, энесе юк! Кычкырып та карый, әле тегендә, әле монда йөгерә, ә энесе юк та юк! Шуннан ул басуга йөгереп чыга; еракта, бик еракта казлар-аккошлар очып барганын күрә. Кошлар тиздән кара урман артына кереп юк булалар. Кыз, минем энемне шулар алып киткәннәрдер әле дип, алар артыннан китә. Казлар-аккошларның бәләкәй балаларны алып китkәләүләрен ишеткәне була аның. Кыз бик озак йөгерә, йөгерә торгач, басуда бер Мич очрата.

— Мич, Мич, әйт әле: казлар кайсы якка очтылар?

— Минем арыш кабартмамны ашасаң әйтәм.

— О, өйдә мин бодайныкын да ашамыйм әле.

Мич кызга берни әйтми. Кыз тагын йөгерә башлый, шулчак бер Алмагачны күрә.

— Алмагач, Алмагач, әйт әле: казлар кайсы якка очтылар?

— Минем кыргый алмамны ашасаң әйтәм.

— О, өйдә мин бакчада үскәнне дә ашамыйм әле.

Алмагач бер сүз дә әйтми. Кыз тагын йөгерә башлый, Сөт елгасына килеп чыга, елганың ярлары кесәлдән ясалган була.

— Елга, Елга, әйт әле: казлар кайсы якка очтылар?

— Кесәл белән минем сөтемне ашасаң әйтәм.

— Юк, өйдә мин каймак та ашамыйм әле.

Елга бер сүз дә әйтми. Кыз тагын йөгерә башлый. Аңа басулар буенча бик күп йөгерергә, урманнарда бик күп адашып йөрергә туры килгән булыр иде, бәхеткә, Керпе очрый. Ул аны тибеп җибәрмәкче була, ләкин энәләре кадалудан курка, шуннан соң:

— Керпе, Керпе, күрмәдеңме син казларның кайсы якка очканын? -ди.

— Мин күрүен күрмәдем, — ди Керпе.

— Шулай да мин сиңа бер йомгак бирәм, ул кая тәгәрәсә, син шунда бар, казлар-аккошларны табарсың.

Кыз, Керпегә рәхмәт әйтеп, йомгакны ала да аны тәгәрәтеп җибәрә, ул бик тиз тәгәрәп китә, Кыз аның артыннан йөгерә башлый. Йомгак, тәгәри-тәгәри, урманга килеп керә. Урманда тавык аяклары өстендә, төрле якка борылгалап, бер йорт тора. Йорт эчендә Убырлы карчык — сөяк аяк утыра. Ә Кызның энесе тәрәзә каршында сәкедә алтын йомыркалар белән уйнап утыра. Апасы бәләкәй энесен күреп ала, посып кына килә дә күтәреп алып китә. Убырлы карчык башын күтәреп караса — малайдан җилләр искән! Ул алар артыннан куарга казларны җибәрә. Казлар-аккошлар очып китәләр, Кыз артыннан куалар болар. Инде кая барырга?Алда Сөт елгасы агып тора, ярлары гел кесәл генә. Кыз аңа:

— Елга, Елга, яшер мине! — ди.

— Аша минем кесәлне!

Башка чара юк, Кыз ашый. Елга аны яры астына яшерә, казлар күрмичә очып узалар. Кыз, качкан җиреннән чыгып, Елгага рәхмәт әйтә дә энесе белән алга таба китә. Ә казлар кире очып киләләр, тагын боларны очраталар. Инде нәрсә эшләргә? Кыз Алмагачны күреп ала.

— Алмагач, Алмагач, яшер мине! — ди.

— Минем кыргый алмамны аша!

Кыз тиз генә алманы да ашый. Шунда Алмагач аны ботаклары белән ышыклый, яфраклары белән каплый, казлар аны күрмичә очып китәләр. Кыз моннан чыга да энесе белән тагын алга йөгерә башлый, казлар аны тагын күреп алалар, тагын артларыннан куа башлыйлар. Шул арада Кыз юлда бер Мич күреп ала.

— Мич, Мич, яшер мине!

— Минем арыш кабартмамны аша!

Кыз тиз генә кабартманы ашый да энесе белән Мичкә кереп утыра, һәм Мичнең капкачы ябыла да. Казлар кычкыра-кычкыра очып йөриләр-йөриләр дә, бернәрсә таба алмагач, кире очып китәләр. Ә Кыз, энесен алып, өйгә йөгерә. Тиздән этисе белән әнисе дә базардан кайтып керәләр.

**Йомры күмәч** (Рус халык әкияте)

Борын-борын заманда бер әби белән бабай бик тату гомер кичергәннәр. Бервакыт бабай, әбигә карап:

— Карчык, күмәч пешерер идең, - дигән.

— Нәрсәдән пешерим соң? Он юк бит.

— Их, карчык, әрҗә төбеннән кырып, бура почмакларыннан себереп кара, бераз җыймассыңмы?

Әби, кечкенә генә канат белән әрҗә төбеннән, бура почмакларыннан себереп, бер-ике уч он җыйган. Шул оннан күмәч пешергән һәм тәрәзә төбенә суытырга куйган.

Күмәч, тәрәзә төбендә тора торгач, кинәт сәке өстенә тәгәрәп төшкән. Сәке өстеннән идәнгә, идән буенча ишеккә, аннан, бусага аша сикереп, өй алдына, өй алдыннан тышкы баскычка, тышкы баскычтан ишегалдына, ишегалдыннан урамга чыгып, юл буйлап тәгәрәп киткән. Күмәч шулай тәгәрәп барганда, каршысына бер Куян килеп чыккан:

— Күмәч, Йомры күмәч, мин сине ашыйм!— дигән аңа Куян.

— Син мине ашама, кылый, мин сиңа җыр җырлармын,— дигән дә күмәч, шундук җырларга тотынган:

Мин — Йомры күмәч, Йомры күмәч,

Әрҗә төбеннән себерелгән, каймакта басылган.

Мин әбидән дә киттем, мин бабайдан киттем,

Синнән дә, Куян, кыен булмас качуы, — дигән дә тәгәрәп китеп барган, Куян аны күреп кенә калган...

Йомры күмәч һаман тәгәрәгән дә тәгәрәгән. Менә бервакыт аның каршына Аю килеп чыккан:

— Йомры күмәч, Йомры күмәч, мин сине ашыйм! — дигән аңа Аю.

— Син мине ашама, Аю дус, мин сиңа җыр җырлармын, — дигән дә күмәч, шундук җырларга тотынган:

Мин — Йомры күмәч, Йомры күмәч.

,Әрҗә төбеннән себерелгән,

Каймакта басылган.

Мин әбидән дә киттем,

Мин бабайдан киттем,

Мин Куяннан да качтым,

Синнән дә, Аю, кыен булмас качуы, — дигән дә тәгәрәп китеп барган, Аю аны күреп кенә калган...

Йомры күмәч һаман тәгәрәгән дә тәгәрәгән, аның каршына Төлке килеп чыккан.

— Исәнме Йомры күмәч, син нинди гүзәлсең! — дигән Төлке. Аңа каршы Йомры күмәч җырлый башлаган:

Мин — Йомры күмәч, Йомры күмәч,

Әрҗә төбеннән себерелгән, каймакта басылган.

Мин әбидән дә киттем, мин бабайдан киттем,

Мин Куяннан да качтым,

Мин Аюдан да качтым,

Синнән дә, Төлке, кыен түгел китүе!

— Һай, нинди матур җырлыйсың икән! — дигән Төлке.- тик мин картайдым инде, бик начар ишетәм: яле, якынрак килеп, минем борыным өстенә утырып, тагын бер генә тапкыр җырлап күрсәт әле. Кычкырыбрак җырла.

Күмәч Төлкенең борын өстенә менеп утырган да шул ук җырны кабатлаган.

— Рәхмәт, бик әйбәт җыр икән. Мин тагын да тыңлар идем. Минем телем өстенә утырып, соңгы тапкыр җырлачы!- дигән Төлке һәм телен чыгарган. Йомры күмәч Төлкенең тел өстенә сикереп менгән икән, Төлке аны капкан да йоткан!

**Төлке белән Аю** (Мари халык әкияте)

Бервакыт Төлке белән Аю юлда калач табып алганнар. Урман йортына кереп, калачны урталай бүлгәннәр. Төлке үз өлешен шундук ашап бетергән. Ә Аю кабып кына караган да соңрак ашарга калдырган. Йокларга яткан болар. Аю хырылдый башлауга, Төлке аның өлешен дә ашап куйган. Төнлә Аю уянган. Калачын ашарга теләгән. Аюның бик каты ачуы килгән.

— Болай булгач, мин сине ашыйм, Төлке, — дигән.

— Гаеплемен, абзыкаем, синең алда. Ашасаң ашарсың инде. Әмма минем итем пешергәч тәмлерәк була, — ди икән Төлке.

— Мич кабызырга ут юк ич!

— Әнә бит ут, — дип, айга күрсәтә икән Төлке.

— Ул ут бик биектә ич, алып булмый.

— Биеген биек тә соң, әнә теге чыршы башына менсәң алып була! Мен, абзыкаем, курыкма, — дип үгетли моны Төлке.

Аю кулына чыра тота да чыршы башына үрмәли. Чыраны айга сузып карый, буе җитми.

— Ыграк үрел, абзыкаем! — дип өйрәтә Төлке тегене, җирдән торып, - әз генә үреләсең калды. Сикер, сикер, шундук җитәсең!

Аю Төлкене тыңлап сикергән икән, чыршы башыннан түбән тәгәрәгән. Әз генә үлми калган, ә Төлке табанын ялтыраткан.

**Аю белән бал кортлары** (башкорт халык әкияте)

Борын-борын заманда, яшәгән, ди, бер кәкре аяклы аю. Аның койрыгы, төлке койрыгы кебек үк, озын да, йөнтәс тә, күпереп торган ди.

Аю бал яраткан. Балсыз яши дә алмаган. Гел бал ашау турында уйлап йөргән. Бал кортлары мыжлап торган агач куышын күрүгә, аюның шатлыгы эченә сыймый башлый икән. Ул, аушаңлап, агач башына менә дә, умартаны пыр туздырып, бал ашарға тотына икән. Бал кортлары аюны сырып алалар да чагарга маташалар, әммә булдыра алмайлар. Чөнки аюның йоны озын, ә бал кортларының каялары кып-кыска. Алар, аюның тәненә яҡынлашырга тырышып, йон арасына энәләре белән керәләр дә шунда сырмалып бетәләр. Ә аюга шул ғына кирәк тә. Ул агачан төшә дә җирдә аунай башлай. Йон арасында буталып калган бал кортлары изеләләр дә бетәләр. Алай да булмаса, суга барып бер чумып ала да, бал кортлары шунда сыланып, коелып төшеп калалар икән. Шунан соң аю янә агач башына менеп китеп, солоктагы бал беткәнче, үзенең эче күпкәнче, сыйлана икән, ди.

**Тычкан белән Чыпчык** (Удмурт халык әкияте)

Яшәгән, ди, Тычкан белән Чыпчык. Талашмаганнар, әрләшмәгәннәр, киңәшсез бер эшкә дә тотынмаганнар, кыскасы, бик дус яшәгәннәр болар. Шулай берчак алар юлда өч бөртек арыш тапканнар. Уйлаганнар-уйлаганнар да бу өч бөртекне басуга чәчәргә булганнар. Тычкан, сукага җигелеп, җир сөргән, ә Чыпчык тырмалаган. Көзен арыш каерылып уңган. Тычкан үткен тешләре белән игенне урып та алган, Чыпчык җитез канатлары белән көлтәләрне җәһәт кенә сугып та куйган. Уңышны бөртекләп җыйгач, бүләргә тотынганнар болар. Бер бөртек - Тычканга, икенчесе- Чыпчыкка, өченчесе- тагын Тычканга, дүртенчесе - Чыпчыкка... Шулай тигезләп бүлә торгач, бер бөртек артып калган. Тычкан болай дигән:

— Җир сөргәндә, тәпиләремне, борынымны канатып бетердем, бу бөртек миңа тиештер инде...

— Юк, бу бөртек миңа тиеш. Җир тырмалаганда, бөтен канатларым эштән чыкты, — дигән Чыпчык.

Озак бәхәсләшкәннәрдерме, белмим, ләкин ахырда Чыпчык теге арыш бөртеген томшыгына алган да очып киткән. Тычкан аның артыннан куа чыкмаган. Ул үзенә тигән өлешне иплэп кенә өненә ташып куйган. Аннары Чыпчыкның кайтуын көтә башлаган. Бер бөртегенә дә тимичә, аның өлешен саклаган. Ләкин, күпме көтсә дә, Чыпчык кире очып кайтмаган. Кыш буе муллыкта яшәсә дә, Тычкан үз өлешен дә ашап бетерә алмаган. Ә Чыпчык, салкында туңа-туңа, ишегалды саен ризык эзләп йөргән. Әле һаман Чыпчык ишегалды саен теләнеп йөри, ә Тычкан үз өнендә аның өлешен саклап утыра, ди.

**Карт белән ялкау егет (чуаш халык әкияте)**

Борын заманда ярлы гына бер карт кеше була. Бу картның карчыгыннан башка беркеме дә юк, ди. Язлар үтеп, печәнгә төшәр вакытлар килеп җиткәч, карчыгы әйтә картка:

— Бар, карт, күрше авылга барып, берәр кеше эзләп кара, печән өстендә үзенә ярдәмче булыр иде», — ди.

Карт күрше авылга китә, йөри торгач, бер яшь кенә егетне очрата бу.

— Улым, ди, миңа бер ярдәмче кирәк иде, ди, әллә вакытлы гына булса да ялланасыңмы?- ди.

— Юк, бабай, яллана алмыйм, — ди егет, - минем бик озак киенә торган гадәтем бар,- ди.

Бабай әйтә:

— Анысы гына бернәрсә дә түгел, минем үземнең дә су эчеп исерә торган гадәтем бар,- ди.

— Алай булгач, безнең икебезнең дә шундый гадәтләребез бар икән, ялланам мин сиңа, — ди егет.

Яллана бу егет. Бабай аны өенә алып кайта. Иртән торып чәй эчәргә утыралар. Бабай тиз генә ашап-эчә дә, ишек алдына чыгып, кирәк-яракларын хәзерләп, яңадан егет янына керә. Бу кергәндә, егет бер чабатасын да киеп бетермәгән була әле. Шуннан соң карт:

— Ярар, улым, мин бара торыйм, син фәлән-фәлән юл белән барсаң, мине табарсың», -ди дә чалгыларын күтәреп чыгып китә.

Ә егет менә кия, ди, чабатасын, менә кия, ди, төш вакыты килеп җитте дигәндә генә, бер чабатасын киеп бетереп, икенчесен кияргә тотынды, ди, бу. Кояш баеп бабай эштән кайтып кергәндә, икенче чабатасын киеп кенә бетереп утырадыр иде, ди; кичке ашны ашап бетерү белән, егет тиз генә чишенде дә, ди, яту белән йокыга да китте, ди. Егет йокысына китү белән, карт әйтә карчыгына:

— Иртәгә мин синнән су сорармын, син: «Су әнә чиләктә, бар да эч», диярсең, — ди.

Иртә белән болар, йокыдан торып, ашап-эчәләр дә егет тагын идән уртасына чабатасын кияргә утыра. Бабай карчыгына әйтә:

— Кая, карчык, су бир әле, сусыным басылмады, — ди.

Карчыгы әйтә:

— Су чиләктә, ал да эч, — ди.

Бабай чиләктән бер чүмеч су ала да эчеп җибәрә. Суны эчеп тә җибәрә, исерә дә башлый. Бабай, бик каты исергән булып, башта стенага килеп бәрелә. Шуннан соң, мич янына барып, бер бөтен кирпечне ала да, тияр-тимәс кенә итеп, егеткә ыргытып җибәрә. Кирпеч стенага барып тия. Егет, бик каты куркып, сикереп тора да ишек алдына йөгереп чыгып китә. Карчык артыннан чыга:

— Улым, нишлисең, кая барасың? —ди.

— Әй, әби, эш харап, — ди егет, — бабай исерде бит, ул миңа яхшылык күрсәтмәс, өйдә калган сыңар чабатам белән чолгавымны чыгарып кына бирсәнә, — ди.

— Ашыкма, улым, — ди әби, — бабаң бераз тынычлангач, өйгә кереп, идән уртасына утырып, иркенләп киенерсең әле, — ди.

— Юк, әби, — ди егет, — зинһар өйдә калган чабатамны чыгарып бирә күр, бабай чыкканчы киенеп куяр идем, — ди.

Әби егетнең чабаталарын чыгарып бирә. Күп тә үтми, бабай бәреләсугыла тышка чыгып килә. Аны күрү белән, егет, чабаталарын тотып, абзарга таба йөгерә дә, тиз генә киенеп тә ала. Бабай моны күргәч айный башлый. Болар икәүләп печән чабарга китәләр. Печән чабып кайтып, әйбәтләп ашап-эчеп, йокларга яталар. Икенче көнне егет, идән уртасына утырып, озак-озак итеп киенә башлаган иде, ди, бабайның: «Карчык, су кая, су!» — дип кенә кычкыра башлавы була, егет чабата киндерәсен бәйләми чыга да йөгерә. Кая туры килде шунда тиз генә киенеп ала да, бабай белән бергәләп китәләр болар. Шулай итеп, бабай егетнең ялкаулыгын ташлатты, ди.

## Төлке белән торна (Мордва халык зәкияте)

Төлке белән торна бик дус булганнар. Бердәнбер көнне алар бәхәсләшә башлаганнар: кайсыбыз хәйләкәррәк дип. Төлке әйткән:

— Мин җитмеш җиде тапкыр иң хәйләкәр!

— Ә мин бер генә тапкыр, ләкин минем хәйлә синең барлык хәйләләреңне җиңәчәк,- дигән торна.

Шулчак, аларны этләр белән аучылар чолгап алган. Төлке анда-монда йөгерә башлаган, ә яшеренергә урын тапмаган. Ә торна качмаган, җиргә яткан һәм үлгән булып кыланган. Этләр аның яныннан киткәннәр һәм төлке артыннан йөгергәннәр. Торна төлкегә ярдәм итәргә булган. Ул һавага күтәрелгән, очып барган һәм этләр алдында җиргә төшкән. Этләр төлкене калдырып торна янына йөгергәннәр. Ә торна канатларын селкетеп, очарга җыенган, ләкин оча алмаган кыяфәт чыгарган. Этләр якынаюга торна җирдән этелеп киткән һәм югары-югары күтәрелгән. Шулай итеп, торна төлкене коткарган. Шул вакыттан бирле ул барысына да хәйләкәр торнадан да дөньяда беркем дә юк дип әйтә ди.

# V I бүлек

## Балалар өчен
## бәйрәм иртәләре

**Тема: Дуслык ярминкәсе**

**Максат:** Балаларда Татарстан Республикасында яшәгән төрле милләт халыкларына карата кызыксыну, туган телебезгә хөрмәт тәрбияләү.

**Тәрбияви бурыч:** Үзеңнең милләтеңә һәм башка милләт халыкларына карата хөрмәт, дуслык хисләре, ватаныңны сакларга әзер була белү күнекмәләре тәрбияләү;

**Үстерелешле бурыч:** балаларның акыл, логик фикерләү тизлеген һәм сөйләм телен һәм сүз байлыгын үстерү; хезмәттәшлек, түземлелек кебек социаль – коммуникатив сыйфатларны формалаштыру.

**Белем бирү бурычы:** Татарстан Республикасында яшәгән төрле милләт халыклары турында балаларның белемнәрен баету.

**Җиһазлар:** татар, рус, башкорт, чуаш, удмурт, мари, мордва костюмнары, аудиоязмада шушы халыкларның җыр һәм бию көйләре, һәр милләткә милли бизәкләр ашъяулык капланган һәм хөнәрчеләрнең кул эшләнмәләре куелган түгәрәк өстәлләр, кул эшләнмәләре: әзерләгән хәситә, беләзек, магнит беркетелгән агачка уеп ясалган аю

**Бәйрәмнең барышы**

**Мәрьям:**

Сандугачкай, сайра,сайра,

Котлап безнең таңнарны.

Туган телдәй газиз бер тел

Дөньяда тагын бармы?

**Ранис:**

Күрче, дөнья нинди матур,

Тирә-ягың гөл генә.

Гөлбакчадай ямьле була

Бары туган җир генә.

**Мәрьям:** Исәнмесез!

**Ранис:** Здравствуйте!

**Бергә:** Хәерле көн, хөрмәтле кунаклар!

**Мәрьям:** Исән-имин килеп җиттегезме?

**Ранис:** Мәрьям, бигрәкләр дә матур итеп исәнләшәбез инде!

**Мәрьям:** Әйе шул, Ранис, туган телебез- татар телендә сөйләшү, сәламләү тәнгә шифа, күңелгә рәхәтлек бирә!

**Ранис:** Кеше тормышында аның бөтен гомере буена аерылгысыз төшенчәләр була.

**Мәрьям:** Шуларның берсе -туган тел дип уйлыйм.

**Ранис:** Ул − кешенең дөньяга аваз салган минутыннан соңгы сулышына кадәр янәшә атлый.

**Мәрьям:** Җир йөзендә телләр бик күп. Аларның төгәл санын әйтү дә кыендыр. Шулар арасында үзебезнең туган телебез - татар теле дә бар.

**Ранис:** Телебез иң бай, иң матур телләрнең берсе. Татар теле – үзе бер тылсымлы дөнья.

**Мәрьям:** Безнең сөекле Татарстаныбызда дүрт миллионга якын кеше яши икән.

**Ранис:** Әйе, Мәрьям, алар төрле милләт халыклары. Күпчелеген татарлар һәм руслар тәшкил итә.

**Мәрьям:** Шулай ук башкортлар, чуашлар, марилар, удмуртлар, мордвалар һ.б. халык вәкилләре дә бар.

**Ранис:** Аларның киләчәккә омтылышлары, уй-хыяллары бер-берсенә охшаган кебек.

**Мәрьям:** Һәр халыкның үз теле, үз тарихы, үз гореф-гадәте, мәдәни мирасы, хөнәрчелеге, сәнгать осталары бар.

**Ранис:** Мәрьям, онытып та торам икән бит....Бүген гүзәл Арчабызга төрле җирләрдән халык сәнгате осталары ярминкәгә киләчәк иде бит! Әйдә ашыгыйк1 Бу чараны күрмичә калырга ярамый!

**Мәрьям:**

Килде ярминкә даулап,

Килде ярминкә шаулап,

Бәхет, муллыклар яулап.

Ярминкәгә рәхим итегез!

*Капка ачыла*

**Татар малае:**

Бүген – “Дуслык ярминкәсе”,

Дуслар  жыелды безгә.

Жырлап-биеп, уйнап-көлеп

Бәйрәм итәек бергә!

**Татар кызы:**

Шундый зур безнең базар,

Шундый бай безнең базар.

Базар бай, кесәсе ай-вай.

Дарым- шарым, тәңкә ярым

Күпмегә алсам, шуңа сатам.

Муенсалар, хәситәләр,

Чүәкләр, кулъяулыклар,

Түбәтәйләр, калфаклар.

Кирәкмиме, алмыйсызмы?

Әллә киеп карыйсызмы?

**Татар малае:** Оялмагыз, бүләгебезне рәхим итеп алыгыз! (хәситә бүләк итә)

**Татар кызы:** Яле, рус дусларыбыз, Сезгә дә сүз бирик әле! (рус киеменнән киенгән кыз һәм малай алга чыга, кулларында поднос белән беләзекләр)

**Рус балалары:** Добрый день, дорогие гости!

**Рус малае:**

Сегодня праздник нас собрал

На ярмарку – на карнавал!

Здесь ярмарка дружбы  наступила,

Ребят всех в гости пригласила!

**Рус кызы:**

Тары-бары-растобары,

Есть хорошие товары!

Привезли сюда

Товары самые модные,

Русские народные,

-Аж, поёт душа,

Гляди:  как Гжель хороша!

**Рус малае:**

Мы подарим  вам браслет

Ни у кого такого нет!

Он разноцветный, он простой

Зато заряжен добротой.

В ней капелька русской души

Его надеть предлагаем мы! (браслет бүләк итә)

**Татар кызы:** Рәхмәтебез, хөрмәтебез чиксез сезгә, дуслар!

**Татар малае**: Чуваш дусларга сүз бирик! (чуаш бию көенә чуаш киеменнән кыз һәм малай чуашча биеп чыгалар)

**Икесе бергә:** Сывлах сунатап!

**Чуаш малае:**

Родина наша – это наш дом.

Где мы вместе дружно живем.

Но все мы мечтаем лишь об одном,

Пусть будет мир в нашем доме родном!

**Чуаш кызы:**

Чакыручы барында

Торма капка янында.

Җырлаганга мал җәл түгел,

Җырлап кал яшь чагыңда.

Әйдәгез безнең чуаш халкының  уенын бергәләп уйнап алыйк әле.

**Татар кызы:** Рәхмәт сезгә чуваш дусларыбыз!

**Татар малае:** Башкорт дусларга сүз бирик! (башкорт бию көенә башкорт киеменнән кыз һәм малай башкортча биеп чыгалар. Малайның кулында подноста бал)

**Башкортлар:**  Хаумыхыгыз, дустар!

**Башкор малае:**

Ут күршеләр булып йәшәйбез без!

Окташ безздең телдәр, гәдәттәр

Тынıслак хәм дуслык сәскә атхын

Уртак беззден йердә теләктәр!

**Башкорт кызы:**

Алып килдем сезгә, дуслар,

Күчтәнәчкә башкорт балы:

Чәчәк балы, юкә балы –

Безнең бал ул бик шифалы.

Гәрәбәдәй якты булсын,

Мәңге булсын дуслык балы! (бал бүләк итә)

**Татар кызы:** Рәхмәт сезгә башкорт дусларыбыз!

**Татар малае:** Удмурт  дусларга сүз бирик! удмурт бию көенә удмурт киеменнән кыз һәм малай удмуртча биеп чыгалар.)

**Удмурт балалары:**  Ӟеч нуналэн!

**Удмурт малае:**

Мы ребята озорные

Мы ребята удалые!

Всех на Ярмарку зовём

Мы платочки продаём!

**Удмурт кызы:**

Аз күләмдә яшәсәк тә
Удмурт халкы вәкилләре.

Дуслык кадерен беләбез,

Куляулыклар чигәбез!

Сезгә дә бүләк итеп алып килдек! Рәхим итеп алыгыз! (удмурт бизәге белән кулъяулык бүләк итә)

**Татар кызы:** Рәхмәт сезгә удмурт дусларыбыз!

**Татар малае:** Марый дусларга сүз бирик! (марый бию көенә марый киеменнән кыз һәм малай марыйча биеп чыгалар. Кызның кулында агачтан ясалган сувенир аюлар)

**Марый балалары**: Сәлам юлташ- влаг!

**Марый малае:**

Наш  Татарстан

Дружбой славиться.

Нам жить в Татарстане

Очень нравится.

**Марый кызы:**

Юкә чәчәге файдалы,

Һәркем кайнанып эчә,

Файдасы бар бал кушкач,

Әгәр дә салкын тисә.(юкә чәчәге бүләк итә)

**Татар кызы:** Рәхмәт сезгә марый дусларыбыз!

**Татар малае:** Мордва дусларга сүз бирик! (мордва бию көенә мордва киеменнән кыз һәм малай мордвача биеп чыгалар. Малайның кулында киптерелгән юкә чәчәкләре тутырылган вак пакетлар салынган поднос)

**Мордва балалары:** Шумбра чи!

**Мордва кызы:**

Вы на ярмарку пришли!

Мы товар привезли.

Подходите, покупайте,

Веселитесь от души!

**Мордва малае:**

Безнең халык инде күптән

Урман белән дан тоткан.

Хәтта көчле аюлар да

Мордваларны үз иткән! (сувенирларны бүләк итәләр)

**Татар кызы:** Рәхмәт сезгә мордва дусларыбыз!

**Татар малае:** Килде бүген ярминкәгә,

Төрле җирдән кунаклар.

“Дуслык ярминкәсе” һәрчак

Гөрләтсен дус халыклар!

**РАНИС:**

Төрле-төрле телдә сөйләшсәк тә,

**МӘРЬЯМ:**

Төрле-төрле милләт булсак та,

**ИКЕСЕ БЕРГӘ:**

Тик бер безнең Туган илебез,

Тик бер безнең Туган җиребез!

**“Татарстан Республикасы  гимны”**н барсы да башкара.

Мәңге яшә, газиз Ватаныбыз,
Халкым тели изге теләкләр!
Гомерлеккә якын туган булып
Яши бездә төрле милләтләр.

Күп гасырлар кичкән чал тарихлы
Данлы илем, үзең бер дастан!
Синдә генә безнең язмышыбыз,
Республикам минем, Татарстан!

Цвети, священная земля моя,
Да будет мирным твой небосвод!
Единый дом у нас, одна семья,
Живет в согласии наш народ.

Богатый мудростью седых веков,
Надеждой, верою ты нам стал,
И пусть хранит тебя моя любовь,
Моя Республика, мой Татарстан!

## Тема: Дуслык  бәйрәме -  Праздник  дружбы

**Максат:** Үзенең милләтенә һәм башка милләт халыкларына карата хөрмәт тәрбияләү.

**Бурычлар:**  Мәктәпкәчә яшьтәге балаларның Идел буе халыклары мәдәнияте, аның башлангычы, теле, гореф-гадәтләре, көнкүреше турында күзаллауларын формалаштыру. Балаларның төрле милләт вәкилләре (татарлар, чувашлар, удмуртлар, марилар, башкортлар, руслар), аларның тормыш-көнкүреше, милли ризыклары, кул эшләре, уеннары, бәйрәмнәре турында белүләренә ирешү.

**Җиһазлар:** балаларга милли костюмнар, милли ризыклар, төрле төстәге кулъяулыклар, күке һәм су анасы битлеге.

**Бәйрәмнең  барышы**

А.б.. Торсак та без төрле җирләрдә.

Без яшибез Рәсәй илендә.

Сөйләшәбез төрле телләрдә,

Аңлашабыз дуслык телендә

Үстергән дә безне чын дуслык,

Көч биргән дә безгә чын дуслык.

Дуслык булса яшәр гомергә

Бөтен җир шарында тынычлык.

**Вед.** Сколько нас нерусских у России

И татарских, и иных кровей

Имена носящих не простые

Не простых Российских сыновей.

Любим мы края свои родные

И вовек, не завтра, не сейчас.

Отделить нельзя нас от России

Родина немыслима без нас.

**1 б.** Без-бер илнең балалары,

Барыбыз да дуслар без.

Татарлар, удмурд, марыйлар,

Башкорт һәм руслар без.

Кайсы якта яшәсәк тә,

Чикләр юктыр дуслыкка.
Дуслык булса янәшәдә,

Дошманлык чыгар юкка.

**2 б.**Дус яшәргә кирәк җир йөзендә,

Дуслар кирәк һәрбер кешегә,

Дуслык булса яшәү дә күңелле,

Уңай була һәрбер эшең дә.

**3 б.** Россия – любимая наша страна

Очень и очень большая она.

Россия – Родина, наш дом

Где вместе дружно мы живем.

**4 б.** Наш Татарстан

Дружбой славится.

Нам жить в Татарстане

Очень нравится.

**А.б.** Хөрмәтле кунаклар! Халыклар дуслыгына багышланган “Дуслык бәйрәме” дип аталган кичәбезне  башлап җибәрәбез.

Төрле – төрле телдә сөйлэшсәк тэ,

Төрле- төрле милләт булсак та .

Тик бер безнең туган жиребез,

Тик бер безнең туган илебез.

“Кояшлы ил-безнең ил” җырын башкарып үтик.

Кояшлы ил-безнең ил, безнең ил

Күге аның гел аяз, гел аяз,

Кыш китерсә кыш бабай,

Чәчәк алып килә яз,чәчәк алып килә яз.

Һавасы да, җире дә, җире дә,

Салават күпере дә, күпере дә.

Яңгыры да, кары да

Безгә якын бары да,безгә якын бары да.

Сандугачлы урманы, урманы,

Ашлык тулы кырлары,кырлары.

Бөтен җиргә яңгырый

Безнең бәхет җырлары,

Безнең бәхет җырлары.

**А.б.**  «Идел бит ул, тирән бит ул, тирән бит ул, киң бит ул» дип җырлый татар халкы. Идел елгасы буенча берничә республика урнашкан, аларда төрле  милләт халыклары  яши: татарлар, башкортлар, чувашлар, удмуртлар, марилар, русслар һәм башка милләтләр.

**Вед.** Все эти народы говорят на своём родном языке. У каждой Республики своя столица, свой отличительный знак герб, флаг. Эти все маленькие республики находятся на земле большой России. - А как называется столица России? – Москва.

**А.б.**Барсы тигез,аермыйлар,

Урыс, татар, удмуртны.

Чык уртага, күрсәт сәләт,

Әгәр булсаң булдыклы!

Татар милли киемнәреннән балалалар керә (С. Фатхутдинов «Мин яратам сине, Татарстан» җыры астында)

**1 б.** Без – татарлар,  шушы исем белән

Җирдә яшәү үзе бер бәхет .

Без – татарлар,  яшибез без җирдә

Бар халыклар белән берләшеп.

**2 б**. Ихтирамның зур билгесе диеп

Дусларның табынына.

Халкыбызны амәнәте итеп

Чәкчәк куыйк кунак алдына.

**3 б.**Чәк-чәк табынга куела

Ямьле бәйрәм көнендә,

Иң тәмле ризык санала

Һәрберебезнең өендә.

**Татар милли киеменнән тәрбияче:** Карагыз әле дуслар, кучтәнәч итеп татар халкыбызның милли ризыгын тәмле баллы чәк-чәк алып килдек, кабул итеп алыгыз!!!

**А.б.** Рәхмәт яусын!

Татар милли киеменнән тәрбияче: хәзер татар халык биюен башкарып китәрбез!

**Вед.** Встречаем  гостей из центра России. *(Звучит русская музыка. Выходят дети в русском костюме.)*

**1 р.**А мы живем в России

У нас леса густые

У нас березы белые

И девочки умелые.

**2 р.** И небо наше чистое

И реки наши быстрые.

И Москвы столицы нашей

В целом мире нету краше.

**Вместе:** Приезжайте чаще к нам

Очень рады мы гостям!

**Воспиатель в русск. костюме:** Вам гостинцы- наш круглый, пышный каравай!

**Вед**. Проходите гости дорогие. Спасибо за каравай.*(Русский танец)*

**А.б.** Таң аткач та иң беренче булып

Кояш сибә безгә нурларын.

Бәйрәмебез гөрләп торсын әле

Каршылыйбыз башкорт дусларны.

*(Звучит башкирская музыка. Идут дети в башкирском костюме)*

**Все вместе:** Һаумыһыс, дустар! (Саумысыз, дуслар!)

**1 б.**Татарлар һәм башҡортлар-

Охшаш безнең телләр, гадәтләр.

Тынычлык һәм дуслык чәчәк атсын

Уртак безнең жирдә теләкләр.

**2 б.** Асылташтай кыйммәт хәзинә ул –

Бал кортлары биргән кәрәзләр.

Үзебезнең йөрәк хисен өстәп

Алып килдек, күрше – кардәшләр!

**Воспитатель в башкирск.костюме:** Күчтәнәчкә гәрәбәдәй, хуш исле, үзенчәлеге белән данлыклы башкорт балы алып килдек. Рәхим итегез!

**А.б.** Хөрмәтле кунаклар, түрдән узыгыз! Рәхмәт!

**Воспит.в башкирск. костюме:** Ә хәзер башкорт халык биюен тәкъдим итәбез!

**Вед.** Обратите внимание сейчас к нам выйдут гости из республики Мари Эл.

(Звучит марийская музыка.Идут дети в марийском костюме)

**Все вместе:** Салам юлташ-влаг!

**1 реб.**Много здесь народов дом свой обрели,
Тысячи героев – воспитали мы!
Матушка Россия – Родина моя!
Край ты мой, Марийский – малая земля!

**2 реб.** Всех крупней и сочней

У марийцев овощи

Попробуйте испекли мы

Из картошки перемечи.

**Воспит.в марийском костюме**: Посмотрите, какие пышные, аппетитные перемечи из картошки мы вам привезли!

**Вед.:** Спасибо вам за гостинцы. Проходите, гости дорогие!

**Воспит. в марийском костюме:** Мы дарим вам свой национальный танец!

**Вед.** Мы не можем представить наш праздник без гостей из Чувашии! А вот они! Добро пожаловать! (под чувашской музыки заходят дети в чувашских костюмах)

**1 реб.** Широки поля – души моей отрада.
Я люблю республику свою!
И весенний цвет ее - награда.
О любви леса ее поют.

**2 реб.** Как повезло тебе и мне:

Мы родились в такой стране,

Где люди все-одна семья,

Куда не глянь- кругом друзья!

**Воспитатель в чувашск. костюме:**

Мы привезли вам  знаменитый чувашский пирог с калиной.

**Вед.** Вот теперь мы попробуем знаменитый чувашский пирог с калиной. Проходите, спасибо вам ребята. (Чувашская игра“Солнце и луна”)

**А.б.** Карап тормый ара еракка,

Дуслар килгән безгә кунакка.

Дуслык бит ул- тормыш үзәге.

Дуслык бит ул – бәйрәм бизәге.

Удмурт дусларыбызны  каршы алыйк! (Удмурт милли киеменнән балалалар керә)

**1 р.** Удмуртия зеленая

Леса, леса, леса.

Леса непроходимые,

Суровая краса.

**2 р.** Что прекрасней и милее

Этой ласковой земли

Всюду яблони белеют

И Вятка течет вдали.

**Воспитатель.** Да, уродились у нас яблоки. Привезли мы Вам яблок румяных.

**Вед.** Спасибо, проходите.

**Воспитатель.** А теперь поиграем удмурдскую игру “Ву мурт” в переводе “Водяной”  (Игра”Водяной” )

**1 б** .Ут күршелэр булып яшик гөрләп,

Охшаш безнең уйлар, теләкләр.

Тынычлык һәм дуслык чәчәк атсын

Уртак булсын барлык теләкләр.

**2 б**. Аралар ерак димәгез,

Якын дуслар безгә килегез.

Җиребезнең  суы татлы,

Халкыбызның йөзе якты.

**3 б.** Безнең дуслык нык булсын,

Мәңгелек булсын.

Көннәребез гел шулай

Шатлыклы узсын.

**4 б.** Әйдәгез, бергәләп

Куллардан тотышыйк.

Җир шары- уртак йорт,

Шул йортта дус яшик.

**А.б**. Киләчәктә дә башка милләт вәкилләре белән дус яшик! Дуслык учагыбыз сүнмәсен! Дуслык белән көчле булып яшик! **("Дуслык җыры")**

1.Әй рәхәт биюләр бергәләп

Каршыга чык син дә сеңелем.

Һавалар гел аяз, гүя яз

Гөлбакча шикелле җиребез.

Куш:Шатланып уйныйк та көлик без!

Күмәкләп җырлыйк та биик без!

Әнкәйдәй кадерләп үстергән илкәйгә,

Зур рәхмәт, зур рәхмәт диик без.

2. Дуслар җыр сузалар һәр якта

Дус булып яшәве күңелле.

Һәм безгә кушылып балалар

Җырлыйлар бииләр шикелле.

**Вед.** Пусть будет мир над головой, тогда все дети нашей стране будут счастливы и жить в дружбе. Россия- священная наша держава!

**А.б.** Сабыйлар күңелендә һәрвакыт

Очрашу, бәйрәмнәр еш булсын.

Һәр илдә, һәр җирдә балалар

Бәхеттән, шатлыктан елмайсын.!

## Тема: Дуслар килә кунакка!

**Максат:** Күпмәдәниятле тәрбия бирү.

**Бурычлар:**

1. Үз милләтенә һәм башка милләт халыкларына карата хөрмәт, үзара дуслык, кунакчыллык, үз балалар бакчабыз белән горурлану хисләре тәрбияләү.
2. Балаларның күзаллаулар формалаштыру, сөйләм телләрен үстерү.
3. Балаларны татар, рус, инглиз телләренең нечкәлекләренә өйрәтү.

**Җиһазалар**: Экран, презентация, милли костюмнар, геройлар өчен киемнәр, бию һәм уеннар өчен атрибутлар, милли ризыклар.

**Кичәнең барышы**

**А.б.** Матур итеп елмаеп
Сәламләшик, дусларым.
Малайларым, кызларым,
Исәнмесез, дусларым!
Балалар: Исәнмесез, хәерле көн!
**1 бала:**
Бәйрәм дәрте бүген барыбызда
Куанычлар балкый йөзебездә.
Бәйрәмебез ямен уртаклаша
Зур кунаклар бүген түребездә.
**2 бала:**
Бездә бүген зур бәйрәм,
Бәйрәмнең дә ниндие?!
Барыбыз да көтеп алган
Бакчабызның туган көне!
**А.б.** Әйе, балалар, бүген безнең бакчабызның туган көне! Бакчабызга ничә яшь? (1 яшь)
- Балалар, ә туган көн көнне гадәттә нишлиләр?(Бәйрәм итәләр, кунак чакыралар, торт ашыйлар )
-Әйе шул, балалар, бездә кунаклар бүген бик күп, шулаймы? Ә сез тагын кемнәрне туган көнгә дәшәр идегез? (дусларыбызны, чит төбәктә яшәүчеләрне)
-Балалар, без үзебез нинди төбәктә, нинди республикада яшибез? (Татарстан республикасында) Безнең туган телебез нинди тел?(татар теле). Димәк, без үзара нинди телдә аралашабыз? (татар телендә)
-Балалар, татар теле- безнең туган телебез, Ана телебез. Без аны яратырга , хөрмәт итәргә, сакларга тиеш! Туган телдән тыш башка чит телләрне дә өйрәнергә кирәкме соң?(әйе)

Әйе , балалар, туган телебез- татар теле белән беррәттән, без рус телендә дә иркен аралашырга,үз фикеребезне җиткерә белергә тиеш.Чөнки Татарстан республикасында 2 Дәүләт теле санала.
Балалар, әле бакчабызда сез өченче телгә дә өйрәнәсез бит, шулаймы? Нинди тел өйрәнәсез? (инглиз теле) инглиз телен өйрәнү сезгә ошыймы? Балалар, чит телләрне өйрәнү - бүгенге заман таләбе. Күп телләрне белү- яхшы күренеш. Ләкин ул телләр арасында иң якыны, иң газизе- Туган тел! Һәркемгә үз туган теле якын. Телләр турында һәм күп телләрне белү хакында нинди мәкальләр беләсез, кем әйтә?!
1. "Тел – белемнең ачкычы, акылның баскычы"
2. "Иң татлы тел – туган тел,
Анам сөйләп торган тел"
3. "Бер телдә ун хикмәт,
Ун телдә йөз хикмәт"
4. "Теле барның- юлы бар!"
5. "Телләр белгән илләр гизгән"
6. "Бер тел- бер ачкыч, ике тел- ике ачкыч"
**А.б.** Безнең татар халкы элек-электән кунакларны хөрмәт итеп чакырган һәм матур итеп каршы ала белгән. Әйтегез әле, нәрсә белән каршы алалар? (чәк-чәк белән)
- Ә чәк-чәкне чиккән сөлгегә куйганнар. Кызлар, сөлгеләрегез әзерме? Чигеп өлгерттегезме? (бию, 4 кыз, "Сөлге чигәм")
Рус халык көе. Кунаклар- рус милләте керә (1 баланың кулында коймак)
**1 бала:** Здравствуйте, здравствуйте!
Мы рады поздравить вас!
Как много светлых улыбок
Мы видим на лицах сейчас!
**2 бала:** Чәк-чәк белән каршы алу-
Матур гадәт ул бездә.
Баллы чәч-чәгебездән
Авыз итегез сез дә!
**3 бала:** Ох, какие вкусные
Блинчики у нас,
От чистого сердца
Испекли мы для вас.
И весёлые частушки пропоём сейчас для вас !
*Такмак+частушки*
1.Начинаем петь частушки
Просим не смеяться.
Тут народу очень много
Можем растеряться.

2.Без бит татар балалары
Әйдә җыелыйк әле!
Кунакларга, дус-ишләргә
Җырлап күрсәтик әле!
3.Ваш красивый детский сад,
Много-много здесь ребят!
Все такие разные,
И такие классные!
4.Әйдәгез, түрдән узыгыз,
Бездә кунак булыгыз.
Изгелекле, мәрхәмәтле
Булсын йөргән юлыгыз!
5.Русский наш родной язык,
Он прекрасен и велик!
В нашей солнечной стране
Близок он тебе и мне!
6.Алай да бергә-бергә,
Болай да бергә-бергә.
Дуслар белән бергә булсаң,
Күгәрчен кебек гөрлә!
7.Мы частушки вам пропели
Хорошо ли, плохо ли.
А теперь мы просим Вас,
Чтобы вы похлопали.
*Инглиз көе, Англия кунаклары керә*
Инглизләр: Hello!
Балалар: Hello!
Инглизләр: How are you?
Балалар: Fine, thank you. How are you?
Инглизләр: Great, thank you.
Балалар: Where are you from?
Инглизләр: We are from London!
Балалар: Welcome!
Инглизләр: We brought you cakes.*(кекс бирә)*
*Инглиз халык бию*
Кроко*дил Гена һәм Чебурашка керә.*
**Крокодил:** Исәнмесез, хәерле көн! ”Сандугач” балалар бакчасы балалары!
Бакчагызның туган көнен!
Белеп килдек еректан!
Озын гомер, нык адымнар

Телибез чын йөрәктән!
**Чебурашка:**
Светлый день у всех ребят,
Все пришли как на парад.
С Днем рожденья, поздравляем!
С Днем рожденья, детский сад!
**А.б**. Балалар, туган көн булгач, туган көн булсын! Әйдәгез. “Ак калач” уенын уйнап алабызмы? *(“Ак калач” уены уйнау)*
Бакчаның туган көненә
Без пешердек ак калач.
Бакчаның туган көненә
Менә шулай ул биек,
Менә шулай тәбәнәк.
Менә шундый киңлектә.
Менә шундый тарлыкта.
Ак калач, ак калач,
Теләгәнеңне ал да кач.
**1 б.** Карап тормый ара еракка,
Дуслар килгән безгә кунакка.
Дуслык- безнең тормыш үзәге,
Дуслык- безнең тормыш бизәге.
**А.б.**Уйныйбыз да, җырлыйбыз да,
Дөньялар имин торса,
Авырлыкларны кичәрбез,
Дуслыгыбыз нык булса.

Җыр “Дуслык җыры”
1. Барлык милләт балалары
Җирдә дус булып калсын!
Дуслык җыры күкләргә дә
Өзелмәс юллар салсын!

*Куш.*Әйдә әле, бергәләшеп,
Куллардан тотыйк!
Сөйләшсәк тә төрле телдә-
Тату, дус булыйк!

2.Кайларда яшәсә, торса да,
Бер уйда, теләктә балалар.
Бәхеткә юл ярып, дусларча,
Дуслык күпере салалар.

## КУЛЛАНЫЛГАН ӘДӘБИЯТ


1. Уразман З. Р. – Татар халкының йолалары һәм бәйрәмнәре - Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1992 ел (31-36 б.)
2. Баязитова Ф. Татар халкының бәйрәм һәм көнкүреш йолалары.- Казан: Татар кит.нәшр., 1995
3. Татар халык иҗаты. Йола һәм уен җырлары.- Казан: татар кит.нәшр,.1987
4. Күңел ачыйк бергәләп: Балалар бакчасы тәрбиячеләре һәм музыка җитәкчеләре өчен ярдәмлек.- Казан: Мәгариф, 2003.- 303б.
5. Балачак аланы: Балалар бакчасы тәрбиячеләре һәм әти-әниләр өчен хрестоматия.- Казан: РИЦ, 2011,-560 б.
6. Тылсымлы куллар (журнал), мәктәпкәчә һәм кече яшьтәге мәктәп балары өчен, башлангыч сыйныф укытучылары һәм тәрбиячеләр өчен
7. Фильм "Тәрбия баскычлары" Проект җитәкчесе Идрисова Кадрия Рәис кызы., 2017
8. Иванов В.П., Николаев В.В., Димитриев В.Д. Чуваши: этническая история и традиционная культура. М., 2000.
9. Бусыгин Е.П., Зорин Н.В. Этнография народов Среднего Поволжья. Казань, 1984.
10. Бусыгин Е.П., Зорин Н.В., Столярова Г.Р. Этнодемографические процессы в Казанском Поволжье. Казань, 1991.
11. Трофимов А.А. Чувашская народная Чуваши Татарстана: книга-альбом. Ч., 2006; Иванов В.П.
12. Чувашская энциклопедия, Г.Б. Матвеев, Е.А. Ягафова.
13. Балалар һәм яшүсмерләр журналы «Салават күпере»

http://salavatkupere.com/

14. К.М. Миңнуллин, Ә.Г. Ибраев, Милли-мәдәни мирасыбыз: Мари Эл татарлары. Бәрәңге. – 2 нче басма. – Казан, 2021. – 368 б. – (Фәнни экспедицияләр хәзинәсеннән).
15. Татарская Онлайн- энциклопедия Tatarica 2023.

https://tatarica.org/tat/razdely/respublika-tatarstan